- Балачакта алган тәрбиядер инде. Әти-әни эшкә бик тырышлар иде, безне дә шуңа өйрәттеләр. Әткәй гомере буе Себердә вахта ысулы буенча эшләде. Эштән кайткач, авыл кешеләренә таштан өй салып йөрде. Мин аңа ияреп, булышырга йөри идем. Ул китеп баргач, энем Рәфкать, сеңелем Дания белән әнкәйгә колхоз кырларында суган уташырга йөрдек. Әниебез почтада хат ташучы булып хезмәт итә иде. Ул эштә вакытта салкын көннәрдә әткәй үз куллары белән төзегән ике катлы өйне җылытырга туры килде. Чөнки ул вакытта авылга газ кертелмәгән, өйләр ташкүмер белән ягыла иде. Өстәвенә, күзе күрмәгән әбиебез Кәримәне ашату-эчертү дә безгә йөкләнгән иде, - дип сөйләде.

Бүгенге көндә Хәбировлар гаиләсе бик күп терлек асрап яши. Эштән кыскартылган Ләйлә ире эштә вакытта терлекләрне үзе карый. Дөрес, хәзер инде аңа күптән түгел армия хезмәтеннән кайткан уллары Айрат ярдәм итә. Кызлары Алия бүгенге көндә сөйгән яры Илнур белән Татарстанның Әлмәт шәһәрендә яши. Мин аларга барган көнне Алия кечкенә сабые Самир белән кайткан иде.

Бер яза башлагач, тагын шуны әйтеп үтәсем килә. Хәбировлар

гаиләсе улларына һәм кызларына шәһәрдә фатир сатып алганнар. Йорт хуҗасы Рамил балаларының шунда төпләнеп калуын болай дип аңлатты:

- Хәзер авылда эш юк бит, биредә генә түгел, район үзәгендә дә юк ул. Чөнки көннән-көн оптимальләштерү дигән нәрсә колач җәя бара. Минем Ләйләм дә шуның хакында эшсез калды бит. Үзем дә уналты ел буе эшләгән

урынымнан кыскартылгач, мал табибы һөнәрен үзләштерүем ярап куйды, яңадан шушы эшемә керештем. Хәзерге көндә мин өч авылга хезмәт күрсәтәм.

Терлек асрауга килгәндә, меңмәшәкать белән үстергән авыл продукциясенә урын табып булмый, өстәвенә, бәяләр бик түбән. Авыл кешесенең хезмәтенә хөрмәт калмады. Шуның өчен балаларыбызның читкә китүенә каршы килмәдек инде. Чөнки шәһәрдә эше дә табылып тора. Яшь гаиләләр төрле программалар нигезендә фатирлы була алалар, карьера үсешен дәвам итәргә дә мөмкинлекләр бар.

Дөрес, мин үзем шәһәрдә өч көннән артык тора алмыйм, чөнки анда минем күңелем тарсына, һава җитми башлый. Ләйләм белән бергәләп кунакка баргач, бик тиз авылыбызга кайтып китәбез. Туган җирсез яши алмыйбыз без. Белмим, киләчәктә татар авылларын нинди язмыш көтәдер?!

Әйтергә кирәк, Ләйлә Әбүзәр кызы вакытын бушка сарыф итми, ул нәсел шәҗәрәсен төзегән. Уңган хуҗабикә буларак, өен тәртиптә тота. Биредә һәрчак чисталык, пөхтәлек хөкем сөрә. Өстәвенә, тәмле ризыклар пешереп, гаиләсен сыйлый. Төрле кул эшләре белән дә шөгыльләнә, аллы-гөлле чәчәкләр үстерә, җырларга ярата. Аның репертуарында мәхәббәт темасына, сөекле әнкәйләргә багышланган җырлар урын алган. Ул - Денис авылы Мәдәният йортындагы "Чулпан" ансамбленең һәвәскәр артисты. Рамилә Хәбирова җитәкчелегендәге ансамбль авылда үткәрелгән бәйрәмнәрдә генә түгел, төрле җирләрдә үзенең матур чыгышлары белән призлы урыннар яулау бәхетенә ирешкән. Ләйлә ханым буш вакытларында шигырьләр яза. Аның иҗаты әниләргә, гаиләсенә, балаларына, газиз туган җиренә атап язган шигырьләргә бай.

Хәзер мин аның "Ни кирәк?" дип аталган шигырен тәкъдим итәм.

Ни кирәк соң адәм баласына
Бу дөньяда бәхет тоярга?!
Бер җылы сүз әллә назлы карашмы,
Әллә дуслык, әллә саф мәхәббәтме?
Ә ни кирәк газиз әниләргә -
Бәбиеңнең исән тууымы?

Әллә аның шатланып көлүеме,
Ачык йөзе, тормышта уңышка
ирешүеме?
Шулдыр бәхет якты дөньяда.
Бер-береңне күрү, сагыну,
Гади генә булган хәлләргә дә
Ихлас, чын күңелдән шатлану!

Әйе, Ләйлә Әбүзәр кызы үзен бик бәхетле итеп тоя.

- Янымда яраткан тормыш иптәшем - Рамилем, сөекле балаларыбыз, туганнарыбыз булуы, ә, иң мөһиме, туып-үскән җиремдә гомер итү – боларның барысы да - минем өчен зур бәхет, - ди ул.

Дөрестән дә, мин дә аның сүзләрен куәтләп, шуны әйтергә телим: татар хатын-кызы – ул милләт анасы, диләр. Әйтергә кирәк, бөек татар халкының сөекле улы, тарихка кереп калырлык Батыршаны да гади авыл хатын–кызы тудырып үстергән бит. Минемчә, гади авыл кызы булган Ләйлә ханымның сөйгәне Рамил белән матур гаилә корып, булганына шөкер итеп яшәве, җәмгыятебезгә яраклы, тәртипле балалар тәрбияләп үстерүе бик күпләргә үрнәк итеп куярлык.

РОДНОЕ ПРОШЛОЕ

Эмиль Летфуллович Валиуллин – человек удивительной судьбы. Его родители – сельские интеллигенты, вобравшие в себя лучшие традиции татарского народа: честность, порядочность, неприятие любой несправедливости и, конечно, истинное гостеприимство. Эти качества в полной мере передались и сыну.

Ирек САЙФИЕВ

В 1964 году Эмиль окончил Среднесантимирскую среднюю школу и поступил на факультет механизации сельского хозяйства Ульяновского сельскохозяйственного института. С 1969 года работал на предприятиях Ульяновской области на партийно-хозяйственных должностях: старший инженер, главный инженер, секретарь парторганизации, директор районного автотранспортного предприятия, председатель колхоза, председатель РАПО.

Обстоятельства сложились так, что Эмиль Летфуллович расстался с сельскохозяйственным производством. В 1990 году он был переведен на работу в Ульяновский институт гражданской авиации имени Главного маршала авиации Б.П. Бугаева, где работал и продолжает работать на ответственных должностях, оперативно решая возложенные обязанности, направленные на подготовку высококвалифицированных специалистов для воздушного флота.

Эмилю Летфулловичу 73 года. Но он не по годам бодр, активен, энергичен. Он прекрасный семьянин, вместе со своей женой Рамилей Вазыховной живут в счастливом браке более 48 лет. Вырастили дочь Эльвиру и сына Ирека, которые унаследовали от родителей все их лучшие деловые и человеческие качества. Они подарили родителям четверых прекрасных внуков. Эмиль Летфуллович в быту прост и общителен, у него много друзей.

МЫ РОДОМ ИЗ ДЕТСТВА

...Шел второй послевоенный год. Страна оправлялась от ран, нанесенных войной. Вернулись фронтовики, редко кто без увечья. А сколько их осталось на полях сражений, сколько пропало без вести! Солдатские вдовы хранили похоронки, но где-то в глубине души надеялись, что произошла ошибка, что вот-вот откроется дверь и войдет он, долгожданный живой и невредимый...

А 1947 год принес новые испытания. Среднее Поволжье поразила небывалая засуха. За все лето не выпало ни капли дождя, земля от жары потрескалась, обмелели реки. Старики припоминали 21-й год, унесший тысячи жизней. В Поволжье снова замаячил голод.

В тот год, надеясь на лучший год, Фагиля посадила картошку на двух огородах. Рассчитывали поправить хозяйство, скотину завести. Но сколько бы ни ухаживали, пололи, окучивали – все впустую: на каждом корне выросли 4–5 картофелин с пятикопеечную монету. Невольно тут задумаешься, как прокормить семью. Трое детей, а еще четвертого она носила под сердцем.

Отец его был учителем, директором школы. Одновременно возглавлял партийную организацию колхоза. Приехал он из Ульяновска, где был на августовском совещании учи-

Ученики среднесантимировской средней школы, 1961 г.

Родители Эмиля Валиуллина в санатории

Летфулла Валиуллин с сыновьями

телей, а дома ни крошки хлеба, жена слегла с двусторонним воспалением легких, температура – 40–41 градус. Молока у ней нет, сама плачет от испуга, плачут дети.

По приезде отец срочно отправился обратно, пешком прошел 10 км до станции и обратно. На второй день привез 5 буханок хлеба: помог заведующий облоно, с которым отец был в детдоме в Самаре. В тот же день у соседки родился сын, договорились с ней, что она будет один раз в день кормить грудью и Эмиля.

Помогали кто чем мог. Дедушка с бабушкой продали или обменяли на продукты все, что представляло у них хоть какую ценность. Мать вспоминала, что не верили, что Эмиль выживет, думали: вот-вот умрет. «Ты так хотел жить, и выжил всем смертям назло», – говорила мать.

Так уж устроена человеческая натура, что все тяжелое, плохое из памяти быстро выветривается, остается только светлое. Наверное, чтобы не отягощать дальнейшую жизнь, не носить в себе груз прошлого. Вот и наступивший 1948 год оказался удачным. Уродились хлеба, и картошка удалась на славу, хватило себе да еще на продажу осталось. Купили козу, появилось свое молоко. Чем не жизнь! Словно и не было прошлогодней засухи, голода.

Эмиль, как самый младший в семье, пользовался особыми благами. Что бы ни делал, все сходило с рук. Детство – это целая жизнь. Шустрый, непоседа! То собака укусит, то с печки упадет или с крыши, то на заборе повисит. Вот так незаметно прошли три года.

С трех лет пришло осознание своего места в жизни. Помогал старшим в огороде, полол лук, картошку. Старался делать все на совесть. Любил, когда хвалят за работу, появлялось чувство своей значимости: я тоже могу!

В четыре года научился читать, знал числа, мог назвать время. Тогда же научился играть в шашки, страшно не любил проигрывать. В пятилетнем возрасте пристрастился играть в карты и шахматы. Проигрывал редко.

Дома были распределены обязанности каждого. Отец преподавал в дневной и вечерней школе, был одним из трех учителей в районе с высшим образованием. Одновременно был и секретарем парторганизации колхоза «Путь Ленина». Дома его видели редко, уходил рано, возвращался ночью.

Среднесантимирская средняя школа была настоящим храмом науки для всех татарских сел района и даже ближайших сел соседней Самарской области. Школа была открыта как государственная образцовая школа в 1926 году. Несколько раз она претерпевала реорганизацию, пока в 1958 году не стала средней общеобразовательной школой. В школе трудились прекрасные педагоги-профессионалы. Первый выпуск учащихся состоялся в 1961 году.

Лутфи Валиуллович преподавал в той школе биологию. Этот, казалось бы, скучный предмет он превратил в самый увлекательный. Вместе с учениками создал пришкольный опытный участок – лучший в районе. Расцвел прекрасный яблоневый сад, плодами которого угощались и учащиеся, и жители села. Большую площадь занимала его любимая культура – капуста. На районных сельскохозяйственных выставках его белокочанная всегда занимала призовые места.

Село *Средний Сантимир является ровесником г. Симбирска. Основали его выходцы из Казанского уезда в середине XVII века. Построили по обоим берегам степной речки свои дома. Растили хлеб, держали скотину. Переживали и засухи, и голодны годы. Шли десятилетия, шли века, село разрасталось. В 70-е годы прошлого века насчитывалось более 500 дворов, население превысило 3000 человек. Все пережило старинное татарское село: и революционные события 1917 года, и лихолетье Гражданской войны, и коллективизацию, сопровождавшуюся репрессиями и раскулачиванием, и голод. Выстояли в годы Великой Отечественной войны, сотни жителей не вернулись с полей сражений, сложили головы на чужбине. Сколько вдов и сирот породила война!*

Пришкольный сад с. Средний Сантимир

От войны село оправлялось долго. Эмиль вспоминает 1950 год. Ему три года, братьям 5 и 8 лет, сестре – 10. Отец режет ржаной хлеб и дает каждому по кусочку. Старший брат долго смотрел и расплакался, говорит: хоть бы раз наесться ржаным хлебом. Вот такая она, цена хлеба…

РОДНЫЕ КОРНИ

Есть на свете места, куда хочется возвращаться каждый раз. Это – отчий дом, место, где ты родился, где впервые услышал нежный голос матери, дом, где тебя всегда ждут и всегда тебе рады.

Ему часто снится их старый дом. «Вот заходит отец, мы бежим ему навстречу. Он берет меня, самого младшего, на руки, поднимает до самого потолка. Мать стоит чуть в сторонке и улыбается. Мне весело и немного страшно. И я просыпаюсь…» – вспоминает Эмиль.

Лутфи Валиуллович Валиуллин повидал на своем веку столько, что никому такого не пожелаешь. Родился он в 1906 году в селе Озеро-Кубань (ныне Кошкинского района Самарской области). Семья большая: отец, мать, шесть братьев и одна сестра. Жили не бедно, но и не богато. Сеяли на своей земле рожь и пшеницу. Слава Богу, если своего хлеба до нового урожая хватало.

Беда пришла в 21-м году. Зима выдалась бесснежной, за весну и лето не выпало ни одного дождя. Иссохли речки, от жары потрескалась земля. На полях не вырос даже сорняк.

Этот год вошел в историю как самый голодный во всем Поволжье, народ вымирал целыми селами. Смерть пришла и в дом Валиуллиных. Умерли отец отца, три брата и сестра. Перед смертью отец призвал к себе Лутфи: «Ты самый старший, бери двоих самых младших и иди в Самару. Может, найдешь что-нибудь или сдашь братьев в детдом». Наскребли что-то из еды и отправили их в дальний путь, за 100 километров. Ни денег, ни хлеба. В свои неполные 16 лет отец взял на себя ответственность перед братьями: лишь бы они выжили!

Дошли все-таки до Самары. Им повезло – как беспризорников их забрала милиция и передала в детдом. Так они остались живы.

В детдом приезжал писатель А. Неверов. Встретился и долго беседовал с Лутфи. Так он стал героем известнейшей в стране книги «Ташкент – город хлебный». Его писатель вывел под вымышленным именем Мишка. Всю жизнь берег эту книгу: там всё правда.

В Самаре в детдоме окончил экстренную школу. Поступил в училище, окончил его с отличием. Ему легко давались все предметы. Отсюда его направили преподавателем в Кузнецк в медучилище. Проходит немного времени, и его зачисляют студентом химико-биологического факультета Оренбургского педагогического института.

Но его забирают в армию. Служил на границе в Хабаровском крае. Во время одной из многочисленных стычек с японцами был ранен – пуля прошла навылет через легкое. 22 дня пробыл в санчасти, и снова в строй.

Оренбургский пединститут вместо 5 лет он окончил за 2 года с отличием. Получил назначение завучем в то же Кузнецкое медицинское училище. Через некоторое время его переводят завучем в Саранское медучилище.

Недолго он там поработал. На директора и на него в органы поступил ложный донос. В час ночи за ним явились «люди в штатском» и увезли в камеру предварительного заключения. Суд «тройки» был скорым и суровым: директору дали 11 лет, отцу – 6 лет.

Написал три письма: Сталину, министру просвещения и министру обороны. Но как переслать письма? Выручил пожилой охранник, которому отец поведал о своих злоключениях. Попросил его обязательно бросить письма только в почтовый вагон.

Через пять дней пришел ответ от Сталина: «Немедленно освободить и восстановить в партии». После правительственной телеграммы отец был сразу реабилитирован.

После часа ночи забрали его из тюрьмы и повезли в городской универмаг. Зашли с черного хода, дали ему в руки два пустых чемодана: бери сколько хочешь и чего хочешь.

Оделся во все светлое, каким к ним пришел. Захватил еще туалетные приборы. Больше ничего не взял. Так и пришлось распрощаться с Саранском.

Приехал в Ульяновск, поближе к родине. Зашел в областной отдел народного образования. Встретился

там знакомый по Куйбышевскому педучилищу. Рассказал ему честно о своих мытарствах. Тот посоветовал, что будет лучше поехать в село, там везде есть школы, а учителей не хватает. Предложил на выбор: Денискино Шенталинского района или Средний Сантимир Мелекесского района.

Он выбрал Средний Сантимир. Село очень большое, но грамотных людей мало. Даже в районе людей с высшим образованием было лишь несколько человек.

Отец стал завучем в дневной и директором в вечерней школе. Избрали его и секретарем партийной организации колхоза. Он буквально окунулся в работу, не знал отдыха ни днем, ни ночью.

В 1938 году в возрасте 32 лет он женился на Фагиле. Было ей тогда только 18 лет. В 1939 году у них родился сын, но он мало прожил. В 1940 году родилась дочь. Ее в честь дочери Сталина назвали Светланой. Так он выразил свое глубочайшее уважение Сталину, спасшего его от тюрьмы. Восхищался его мудростью, работоспособностью.

Лутфи вспоминал: «В начале 40-х жизнь в Советском Союзе уже наладилась. Пошли хорошие зарплаты, в магазинах все есть: и продукты, и одежда. Только зажили нормально, а тут началась война...»

Эмиль Валиуллин с родными

Отцу в военкомате дали бронь. Но, несмотря на это, он не переставал обивать пороги военкомата, пока в сентябре 1941 года его не забрали и отправили на Калининский фронт. Выстоял в боях под Ржевом, Вышним Волочком... В июне 1942 года был тяжело ранен осколками бомбы, и его комиссовали. Домой его привезли сержант и два солдата: сам он ходить не мог, не мог поднять и руку. До конца жизни в руке и ноге он носил осколки.

В войну он потерял двух братьев, тех, кого спас в голодном 21-м году. Без вести пропал в 1941-м году военный фельдшер офицер Хасият Валиуллович Аксенов, в июле 1944-го года в боях под Псковом сгорел в танке гвардии лейтенант Нургали Валиуллович Аксенов. Из некогда большой семьи оставались только израненный мой отец и мать. Бабушка тоже умерла в 1943 году.

В 1942 году родился сын, которого назвали Рафаэлем. В 1944 году родился еще один сын – Раиль. В 1947 году родился Эмиль.

Рядом с ним всегда была любимая жена Фагиля. Они делили вместе все радости и невзгоды. Наверное, именно благодаря ее заботе и любви муж вскоре встал в строй. Он всецело отдавался любимой работе в школе, вырастил прекрасный сад, главное – вырастил и воспитал десятки детей, которые впоследствии стали достойным гражданами страны.

Фагиля Насыйбовна родилась в селе Амировка. Она из династии Хафизовых – Бихузиных. В голодный год из семи сестер выжила она одна. Способность к самопожертвованию в нее была заложена с детства. Когда родился Эмиль, она заболела двусторонней пневмонией. Температура выше 40 градусов, а она думает о младенце и детях, у которых нет даже хлеба. Пережила очень многое, бывали дни, когда становилось невыносимо тяжко. Но ни разу дети не видели в ее глазах слезы. Просто улыбалась: все пройдет!

С родными у посаженной Э. Валиуллиным рябины

У нее не было высшего образования, но была она глубоко интеллигентным человеком, как бы доказывая, что интеллигентность не всегда достигается образованностью. С детства она много читала, росла умной и рассудительной не по годам девочкой. Любимыми писателями ее были Джек Лондон, Эмиль Золя, Гумер Баширов, Ильдар Юзеев, Габдулла Тукай. Она перечитала все книги, имевшиеся в сельской библиотеке!

Свою любовь к книге мать привила и своим детям. И еще – любовь к музыке. Рафаэль именно благодаря напевам матери научился сначала подбирать ноты, затем играть на гармони.

«В нашем саду было любимое место бабушки, где росла красная рябина. Ее, еще будучи студентом, посадил Эмиль Летфуллович. Деревце это состарилось вместе с нами, высохло и заново пошла отростками. Папа сделал бабушке скамейку. В последние годы жизни мы часто находили ее там, задумчиво сидящую возле своего любимого куста, потому что посадил когда-то рябину Эмиль – младший сын. Зная это, мы заботились о рябине, каждый раз поливали ее, радуя бабушку», – вспоминает ее внучка Эльмира.

После войны Фагиля всерьез занялась рукоделием, по эскизам и выкройкам шила платья на заказ, приезжали к ней из соседних деревень на лошадях. Ее имя было известно всей округе.

В 1947 году построили крестьянский дом. После войны страна быстро поднималась из руин, жизнь стала налаживаться. Глава семьи зарабатывал хорошие деньги, потому в 1961 году смогли построить новый дом.

Светлана окончила 7 классов и поехала учиться в Сенгилеевское педучилище. После окончания работала и одновременно училась заочно на филологическом факультете Ульяновского педагогического института.

Старший сын после 7-го класса поступил в Рязановский совхоз-техникум на факультет механизации. Второй окончил открывшуюся в 1959 году Среднетерешанскую среднюю школу и поступил на факультет электрификации Рязановского совхоза-техникума.

Э. Валиуллин с женой и детьми

Светлана работала в школе в родном селе. Вышла замуж за учителя родного языка Г.Б. Абуразянова. У них родилась дочь Эльза.

Старший брат после техникума работал главным инженером в колхозе в с. Елховка Кошкинского района Самарской области. После службы в армии женился на И.А. Залаловой, медработнице. Родились у них дочь Эльмира и сын Айрат. Заочно поступил на агрофак Ульяновского сельхозинститута, окончил. Работал главным инженером в откормсовхозе «Куликовский» Новомалыклинского района. Потом переехал в родное село к престарелым родителям. Работал заведующим гаражом, главным инженером, секретарем парткома, заместителем председателя колхоза.

Но пришла перестройка, начался планомерный развал народного хозяйства, ликвидировали колхозы и совхозы, под видом нерентабельных уничтожили заводы и фабрики. Брат тогда собрался и уехал в Ульяновск на авиакомплекс. Приняли его в отдел инженером. Так он и проработал там до пенсии.

Оформил пенсию и сразу вернулся в родное село. Восстановил родной дом, все перестроил, получилось ничуть не хуже городской квартиры: газовое отопление, водопровод, канализация. Дома баня, во дворе колодец. Разумеется, отличный сад и огород. И гараж утепленный. Все под руками. Все сделал сам: он и плотник, и столяр, и сварщик, и строитель. Вот такой он, Рафаэль Валиуллин!

Раиль ушел в армию со второго курса в армию. Служил три года в Венгрии в танковой части. Приехал младшим сержантом, продолжил прерванную учебу. За полтора года окончил техникум, и его направили главным энергетиком в Отрадненскую птицефабрику Ульяновского района. Через несколько лет его перевели главным энергетиком в Новомалыклинскую птицефабрику. Тут строилась новая огромная птицефабрика (в десять раз мощнее Отрадненской фабрики) производительностью 100 тонн мяса птицы в сутки.

Женился, жена З.А. Нуретдинова – врач. Родились дочь Гульнара и сын Рамис. Построили в поселке Майна двухэтажный дом. Все у них складывалось хорошо вплоть до 90-х годов. На фабрике затем начались сокращения работников, в конце концов просто закрыли фабрику. Раиль после этого ушел в предпринимательство.

Жизнь брата оборвалась трагически: погиб в автомобильной аварии. Вместе с ним погибли еще трое: директор, заместитель директора и водитель...

Эмиль Летфуллович на 74-м году жизни продолжает работать. Говорит, что не может без людей, что только на работе душа отдыхает, хоть на время забываются печали и горести…

“ХАЛКЫМА ХЕЗМӘТ ИТҮДӘН ЛӘЗЗӘТ ТАБАМ”

Тольятти шәһәренең татар милли хәрәкәтен искә алсаң, иң беренче чиратта, бу тармакта җан-фәрман эшләүче Сәйхулла кызы Зөлфия Галиханова күз алдына килеп баса. Милли җанлы, татарлар өчен үлеп торучы, чын күңелдән халкыбыз язмышын кайгыртучы Зөлфия апа якты йолдыз булып балкый.

Миләүшә ГАЗИМОВА

Ул - баскан җирдән ут чыгара, дәрт-дәрманы ташып торган ханым! Һәр кешегә ачык йөзле, елмаеп, ихластан сөйләшә, ярдәмчел, һәр эшен җиренә җиткереп башкара, йөрәге тулы мәрхәмәт аның.

Зөлфия ханым - Тольятти шәһәре, Самар өлкәсе татарлары алдында зур абруй яулаган шәхес. Башкаларга ихтирам күрсәтеп яши, үзен дә хөрмәтлиләр, яраталар. Татар халкының милли гореф-гадәтләрен саклаучы милләттәшебез мактауга һәм сокланууга лаек.

Аның хезмәтен түрәләр дә югары бәяләп, аңа Самар өлкәсе Губернаторының, Бөтендөнья татар конгрессының Рәхмәт хатлары, Тольятти шәһәр башлыгының Мактаунамәсе тапшырылган.

Без Зөлфия Галиханова белән сөйләшеп, аның тормышы, милли хәрәкәттәге эше турында сүз йөрттек.

- Зөлфия апа, кайсы якның чишмә суларын эчеп үстегез?

- Мин Дәүләткол авылында тудым. Өченче сыйныфны бетергәч, дүртенче класстан Камышлыга йөреп укырга кирәк иде. Шуңа күрә әти-әнием шунда күченеп урнаштылар.

Мәктәпне тәмамлагач, Богырыслан шәһәрендә медицина училищесында белем алдым. Туган авылыма кайтып, шәфкать туташы хезмәтен башкардым.

Авыл клубында берничә ел режиссер булып эшләдем һәм 2005 елга кадәр андагы барлык чараларны үткәрүдә катнаштым.

Аннары тормыш дулкыннары мине Тольятти шәһәренә китерде. Бүгенге көндә биредә “Автоград” исемле мәдәни үзәктә хезмәт итәм.

- Сез – бик тә шәп, актив

хатын-кыз. Нәселегездә барысы да шундыймы?

- Күбебез шундый. Әти-әнием дә бик уңган-булган, җитез кешеләр иде. Авылда яшәп ятучы энем дә барысын да булдыра. Ул эреп ябыштыручы (сварщик) булып эшли. Хезмәтен бик оста башкара.

- Милли хәрәкәткә кайчан, ничек килеп кердегез? Җәмәгать эшегез турында сөйләсәгез иде.

- Яшь чактан ук җәмәгать эшләрендә актив катнашып килдек. Медицина училищесында укыганда, авылга каникулга кайткач, агитбригадалар белән концертлар куеп йөри идек.

Тольяттида яши башлагач, бервакыт шәһәр татар мөхтәриятендә мәдәни-агарту хезмәте җитәкчесе булып эшләгән авылдашыбыз Раилә Сафина кунакка чакырды. Яңа елны бергә каршы алдык. Шулай автономия хезмәткәрләре белән танышып, дуслашып киттек.

Аннары, Раилә киткәч, мөхтәриятнең рәисе Җәмил Вәлиуллин мине аның урынына эшкә чакырды. Шулай итеп, 2007 елдан бирле анда хезмәт итәм. Алты ел бу оешманың башкарма директоры булдым. Бүгенге көндә дә автономиянең барлык чаларын оештыруда җиң сызганып эшлим.

- Сез – Тольятти шәһәре татар милли-мәдәни мөхтәриятенең 10 еллыгына багышлап, “Сохранить и приумножить” исемле китап чыгардыгыз. Мин, аның макетын ясаучы кеше буларак, сезнең бу хезмәтне җаныгыз-тәнегезне биреп башкаруыгызны күрдем. Кышның салкын, карлы көннәрендә көн саен кичләрен Тольятти – Самар юлын таптадыгыз. Шундый китап бастыру

идеясы ничек барлыкка килде? Халыкны куандырып булдымы?

- Идея әллә кайчан барлыкка килгән иде инде. Тик, акча булмау сәбәпле, тормышка ашырыла алмыйча торды. Һәм, бәхетебезгә, мәрхәмәтле кешеләр ярдәме

белән китапны бастырдык. Бу эшне җитәкләп, башкарып чыгарга кем ярдәм итә алыр икән, дип, "Бердәмлек" гәҗитәсенең баш мөхәррире Рәфкат абый Әһлиуллин белән киңәшкәч, ул, бер дә икеләнмичә, тарихчы Шамил Галимовны тәкъдим итте.

Шамил әфәндегә, Миләүшә, сиңа һәм акча биргән иганәчеләребезгә бик зур рәхмәтләрем. Сезнең белән китапны басмага әзерләгәндә шулкадәр җиренә җиткереп, һәр хәрефне, өтер-ноктаны җентекләп тикшереп эшләгәнегезгә исләрем киткән иде.

Һичшиксез, бу китап халык өчен бик кирәкле булды. Аны укып, күпләр мөхтәриятнең барлыгын белделәр һәм безнең эшләрдә катнашырга теләк белдерделәр.

Аннары бу бит – тарих. 1986 – 1987 еллардан алып, Тольятти татарлары тормышына кагылган мәгълүматлар бирелде анда. Ул вакытта бездә Сабан туйлары уздырыла башлаган. "Туган тел" исемле татар-башкорт җәмгыяте эшләп килгән. Шуларга багышланган материалларны эзләп таптык.

2001 елда шәһәр татар милли-мәдәни мөхтәрияте оештырылды, һәм аны Җәмил Вәлиуллин җитәкләде. Аннары Рәшит Нурмөхәммәтов, Рәүф Кирасиров рәис вазифаларын башкардылар. Бүгенге көндә автономияне Тольятти шәһәренең имам-мөхтәсибе Ислам хәзрәт Гомәров җитәкли.

Төрле елларда төрле журналистлар мөхтәрият, активистларыбыз турында язган мәкаләләрне җыеп, китапка тупладык. 20 көн буена көн-төн эшләргә туры килде. Архивларда утырырга кирәк булды, әлбәттә.

Һәр хезмәтне яратып башкарырга кирәк шул. Нинди эшкә тотынсам да, күңелемне биреп тырыштым.

- Тольятти шәһәренең "Идел" дип аталган җыр һәм бию татар ансамблен җитәклисез. Бу хезмәтегез нәрсәсе белән күңелегезгә якын?

- Мин гомерем буе җыр-моңга гашыйк. Җырлаган кешеләрне, биючеләрне, гармунчыларны яратам. Ата-анам да бик матур җырлыйлар иде. Әни "Ярмәк вагы"н иң оста биючеләрнең берсе булды.

Мин – иҗади шәхес. Вакытында җырладым да, биедем дә, бөтен бәйрәмнәргә сценарийларны үзем яздым.

"Идел" ансамблен җитәкләвем күңелемә рәхәтлек бирә, ләззәтләндерә. Бездә балалар да, олы яшьтәге кешеләр дә бар. Һәрберсе үзенчә сәләтле.

Төрле җирләргә конкурсларга йөрибез. Телевизион тапшыруларда катнашабыз. "ТНВ-Планета" каналында "Җырлыйк әле!" тапшыруында да чыгыш ясадык. Самарда үткәрелгән "Мирас" фестивален калдырганыбыз юк. Талантлы җырчыларыбыз, биючеләребез призлы урыннар яулап киләләр.

"Идел"нең уңышлары – эшебезнең нәтиҗәләре. Бу, әлбәттә, минем өчен зур бәхет булып тора.

- Мөхтәрият нинди чаралар уздыра?

- Бик күп чаралар үткәрәбез без. "Язлар моңы" фестивале, "Татар кызы" бәйгесе, Сабан туйлары, төрле бәйрәмнәргә багышланган кичәләр. Быел беренче мәртәбә 5 – 14 яшьлек балалар өчен аерым "Татар кызы" конкурсын оештырдык.

Мөхтәриятебезне мәчетебез имамы Ислам хәзрәт Гомәров җитәкләгәч, Мәүлид бәйрәмендә дә катнаша башладык, шөкер.

Самар өлкәсе "Ак калфак" татар хатын-кызлары җәмгыятенең филиалы да бездә уңышлы эшләп килә.

Балаларга, яшьләргә бик күп игътибар бирәбез. Олыларның да күңелен күрәбез.

- Зөлфия ханым, Сез уйлап тапкан һәм оештырып килгән "Язлар моңы" татар фестиваленә Бөтендөнья татар конгрессы

югары бәя биргән. Әлеге чара ничә ел үткәрелә, анда кемнәр катнаша?

- Бу бик тә матур фестиваль җиде ел үткәрелде инде. Быел дөньядагы авыр хәлләр аркасында ул оештырыла алмыйча калды.

Әлеге чарада төрле яшьтәге җырчылар, биючеләр, гармунчылар үз осталыкларын күрсәтәләр. Өлкәбезнең төрле почмакларыннан киләләр. Гали, Камышлы авылларында, Сызран шәһәрендә яшәүчеләр бик теләп чыгыш ясыйлар. Ульян өлкәсенең Димитровград шәһәреннән дә еш катнаша-

лар. Яшьләрнең бик күп булуы шатландыра.

- Камышлыда 1988 елдан бирле уздырылган "Уйнагыз, гармуннар!" бәйгесен дә сез оештырып, алып баргансыз икән.

- Әйе, бу чараны без оештырып җибәрдек. Шулай бервакыт ул чакта клуб директоры булган Әгъдәс абый Гыйззәтов, Казанга барып кайткач: "Анда гармунчылар бәйгеләрен үткәрәләр. Без дә бу эшне ерып чыга алырбызмы икән?" – дигәч, мин аңа: "Бөтен нәрсәне дә булдырабыз!" – дип җавап бирдем. Һәм кулыбыздан килде дә.

Ул вакытта авылыбызда 108 гармунчы иде. Шуларның егермесе беренче бәйгедә катнашты, икенчесендә 45 кеше булды.

Шулай ел саен 2005 елга кадәр бу чараны матур гына оештырып килдек. Тора-бара ул район күләмендә үткәрелә башлады. Башта авылларда аерым-аерым узды. Аннан инде иң-иң осталарын сайлап алып, район конкурсы була иде.

Берникадәр вакыт бәйге иң оста гармунчыларыбызның берсе, чараны оештырырга ярдәм иткән физика укытучысы Наил Сафин исемен йөртте.

Иске Ярмәк авылында үткәрелүче "Уйнагыз, Гали гармуннары!" фестивален оештыруда да катнашырга, беренче сценариен язарга насыйп булды. Ул тәүге тапкыр Камышлыда булды. Аннары Ярмәктә уздырыла башлады.

Бу конкурсларның нәтиҗәләре уңышлы, чөнки биредә күп егетләр-кызлар иҗади үсеш алып, тормышта уңышларга ирештеләр.

- Шулай ук 1988 елда драматург Туфан Миңнуллинның "Бер яшьлектә, бер картлыкта" спектаклен сәхнәләштергәнсез. Димәк, Сез – театр яратучылар исемлегендә.

- Әйе, бик тә яратам. Әнием дә бик оста итеп күп рольләрне башкарды. Аның катнашындагы "Ул кайтты" спектаклен әле дә сагынып искә алалар.

"Бер яшьлектә, бер картлыкта" спектакленнән тыш, тагын "Саф күңелгә тап төшмәс", "Карт гашыйк" , "Хаҗи әфәнде өйләнә" спектакльләрен дә куйдым.

- Үзегезнең уйнаганыгыз бармы соң?

- Мин Казанда режиссерлар курсларын, аннары өстәмә белем алу институтында режиссерлык факультетын тәмамладым. Укытучыбыз - Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәевның: "Режиссер үзе спектакльдә уйнарга тиеш түгел", дигән сүзләрен бер дә онытмыйм.

Режиссер бит уйкичерешләрен һәр артист аша тамашачыларга җиткерергә тиеш. Әгәр дә спектакльдә катнашса, үзенең роленә басым ясап, калганнарга игътибар кими төшәчәк.

Ә болай яшь чакларда уйнадым. "Күршеләр" спектаклендә катнашканымны хәтерлим.

Әле тугызынчы сыйныфта укыганда ук Гәрәй Рәхимнең "А-ля-Шәр туны" исемле хикәясен сәхнәләштергән идем. Аны күрше авылларга да барып күрсәттек. Класс җитәкчебез Мөзәгит абый Бәдретдинов та – сәнгатьне яратучы кеше иде.

- Димәк, режиссерлык сәләтегез ул вакытта ук бәреп чыккан. Балачакта кем булырга хыяллана идегез соң?

- Артист булырга теләдем. Мәктәптән соң укырга керергә ниятем дә бар иде. Тик ул вакытта бу һөнәргә андый хөрмәт юк иде. Әти-әнием моны игътибарга алмадылар, шаяртып кына куйдылар.

- Театр турында сүз кузгаткач, бу темага кагылышлы бер гамәлегезне искә төшереп алыйк инде. Сез Камышлы татар халык театрының 80 еллыгы хөрмәтенә "Яучылар" спектакленең телевизион версиясен ясатып, дискларны халыкка тараткансыз. Бу – үзенчәлекле идея. Ул ничек барлыкка килде һәм ничек тормышка ашырылды?

- Без ул спектаклне Камышлы халык театрының режиссеры Гүзәлия Шакирова белән сәхнәгә куйган идек. Тамашачылар аны елына ике тапкыр карап бардылар. Ул вакытта эшләгән җирле "Нур" телевидениесеннән дә күрсәтеп тордылар. Шуңа да карамастан, һәр спектакль аншлаг белән узды. Халыкка шулхәтле ошады ул. Өч ел сәхнәдән төшмәде.

Шуннан мин ул вакытта клуб мөдире булган Раилә Сафинага һәм мәдәният идарәсе җитәкчесе Эдуард Сафинга мөрәҗәгать иттем. "Артистларыбыз бу спектакльдә бигрәк оста уйныйлар. Тамашачылар да бик яратты. Әйдәгез, аның телевизион версиясен ясатыйк", - дип, тәкъдим иттем. Алар ризалаштылар. Бу үзенә күрә бер зур вакыйга булды.

- Зөлфия апа, Сез – чын

мәгънәдә татар халык горефгадәтләрен саклаучы ханым. Самар өлкәсендәге "Милли туйлар" фестивалендә актив катнашып, ЗАГСта никахны татар йолалары буенча рәсмиләштерүдә дә хезмәт куясыз.

- Әйе, бу эшне ел саен сентябрь аенда башкарып киләбез. Иң беренче үз авылыбыз ЗАГСында Камышлы халык театрының артистлары белән туй йолаларын күрсәттек. Аннары Тольяттида да катнаша башладык. Автозавод районы ЗАГСында, бал-май каптырып, көянтә белән суга барып, биючеләрне, җырчыларны, гармунчыларны чакырып, әлеге чараны бик матур итеп үткәреп киләбез.

- Сез матур-матур мәкаләләр дә язасыз бит әле. Журналист сәләте кайдан килгән икән?

- Үземне журналист, дип санамыйм мин, күңелем тулган чакларда мәкаләләр язгалыйм. Моңа сәләт кайдан килгәндер инде, белмим. Мәктәптә иншаларны бик яхшы яза идем.

Һәрбер мәкаләмне бөтен күңелемне биреп иҗат итмәсәм, ул тулы булмый кебек. Яфракның ничек селкенәненә кадәр җентекләп язсам гына, кичерешләремне күрсәтә алам.

- Үзегез татар телен камил беләсез. Балаларыгызга, оныгызга ана телен өйрәтеп булдымы?

- Әйе, шөкер, барысы да саф татарча сөйләшәләр. Татар шигырләрен, җырларын яраталар. Гаиләбездә гел ана телебездә аралашабыз.

- Сезнеңчә, нарасыйны татар теленә ничек өйрәтергә?

- Ана сөте белән керергә тиеш ул. Әни кешегә бала әле карынында чагында ук татар телендә сөйләшергә, җырлар җырларга кирәк.

Баланы сабый вакытыннан әти-әнисе ана телендә сөйләргә өйрәтергә тиеш. Гаиләдән башларга! Өйдә гел татарча аралашырга. Шул вакытта гына нәтиҗәләрен күрергә була.

Без Бөтендөнья татар конгрессы оештырган төрле чараларга йөрибез. Анда чит илләрдә яшәүче татарлар да килә. Алар үз илләренең дәүләт телен һәм ана телен генә беләләр. Бездән дә яхшырак итеп саф татарча сөйләшәләр! "Өйнең бусагасын атлап кергәч тә, тик татар телендә генә сөйләшәбез", - диләр.

Гаиләдә нинди телдә аралашалар, бала шуны өйрәнеп үсә!

- Коронавирус пандемиясе мөхтәрият эшенә дә үзгәрешләр керткәндер?

- Әйе, чараларыбыз кичектерелеп тора. "Язгы моңнар" фетиваленә тулысынча әзерләндек. Бер-ике көн генә калган иде. Аны да үткәреп булмады. Сабан туйлары да узмады бит инде.

Шулай да "Автоград" мәдәни үзәгебездә онлайн форматында концертлар күрсәттек. Балаларыбыз да шигырьләр сөйләгәннәрен, җырлаганнарын видеога төшереп җибәрделәр. Шулай итеп, аралашу бөтенләйгә тукталмады.

- Сез – иҗади кеше. Мондый шәхесләргә нинди сыйфатлар хас?

- Мин - хисле, туры әйтә торган кеше. Кечкенә чактан ук алдаша белмим, һәрчак дөресен әйтәм.

- Ә башкаларда нинди сыйфатларны өстен күрәсез?

- Гадел, намуслы, күркәм холыклы шәхесләрне якын итәм. Сиңа турыга әйтсеннәр. Кеше аркылы ишетү авыр бит ул. Без гаиләдә дә ошамаган нәрсәне уртага салып сөйләшәбез. Әти-әниләр заманыннан ук шулай.

- Тольятти татарларының милли үзаңын ничек бәялисез?

- Тольяттидә яшәүчеләр – төрле төбәкләрдән килгән халык бит. Һәрберсенең үз менталитеты, үз культурасы. Без һәр кешенең үзенчәлеген кабул итә белергә тиеш.

Татарлар арасында төрлеләре бар. Кемдер милли җанлы, татар халкы өчен янып-көеп яши. Кемдер битараф.

Мине шунысы куандыра – яшьләребезнең, балаларыбызның милли үзаңы бар. Менә, мәсәлән, безнең мөхтәрият эшендә катнашкан нарасыйларны гына алыйк. Алар вата-җимерә булса да, татарча сөйләшәләр, милли чараларда катнашырга ашкынып торалар. Һәр сүзеңне тыңлап, ышанып, күңелләрен биреп тырышалар, аңламаганнарын сорыйлар.

- Татарларыбызның киләчәге бармы?

- Бар. Безнең халкыбыз әз генә сүнеп-сүрелеп торса да, яңабаштан ялкынланып, янып китә.

Үзен татар дип санаган һәрбер кеше ана телендә сөйләшергә, милли мохиттә яшәргә тиеш. Балаларны да шуңа өйрәтергә кирәк.

Үзләре татарча белмәгән ата-аналар да балаларын безнең мөхтәрияткә китерәләр, аларга ана телен өйрәтергә телиләр.

Төрле чакларны күрергә туры килде. Соңгы елларда милләтебезгә, татар теленә игътибар күп бирелә, шөкер. Шатлыгыбызга, Тольяттида безне түрәләр дә хуплыйлар, төрле чараларга чакырып торалар, нинди генә сорау белән барсак та, булышырга тырышалар, Сабан туйларын уздырырга да ярдәм итәләр.

Татарны беркайчан да баса алмаганнар. Милләтебез яшәячәк. Әлбәттә, үзебезгә дә бик күп тырышырга, киләчәк буында милли үзаң үстерергә кирәк.

- Тормышыгызда иң бәхетле вакыйгалар нинди булды?

- Тормыштагы һәр мизгелне татып яшәү – минем өчен бәхет.

- Бүгенге татар яшьләре нинди, дип уйлыйсыз? Аларда өмет бармы?

- Әйе, өмет бар. Алар бөтенесен булдыралар, үзләренә дөрес юл күрсәтергә генә кирәк. Алда әйтеп үткәнемчә, безнең мөхтәрияткә йөрүче балаларның күбесе татарча белми, әмма үзләштерергә тырышалар. Елап-елап татар телендәге чараларда катнашырга телиләр.

Без, гомумән, нарасыйлар, яшьләр белән бик күп эшлибез. Моның өчен, шөкер, мөмкинлекләребез дә бар. Башка җирләрдә андый юк әле – безнең мөхтәриятнең үзенең ике катлы зур бинасы бар, җиһазландырылган. Аппаратура да үзебезнеке. Репитицияләр, җыелышлар уздырыр өчен урын эзләп йөрергә түгел. Аллаһыга шөкер.

- Сезнең үз балаларыгыз да милли хәрәкәттә актив катнашалар, дип беләм.

- Әйе, кызым Алия - бүгенге көндә шәһәр мөхтәриятендә мәдәни-агарту хезмәте җитәкчесе. Бөтен эшне үзе алып бара, барысына да өйрәнде, тырышып, ярытып хезмәт итә. Бәйрәмнәргә сценарийлар да яза, үзе оештыра да, театральләштерелгән тамашалар әзерли.

Алия күбесенчә яшьләр, нарасыйлар белән эш итә. "Кояшкай" исемле балалар ансамблен җитәкли. Үзләрен төрле төбәкләргә чараларга алып бара. Мәскәүдә Нәүрүз бәйрәмендә дә булдылар. Казанга лагерьларга да йөриләр.

Мөхтәрияттә бөтен гаиләбез эшли. Һәрберебезнең үз вазифасы бар.

Улым Алмаз җырлый. 2017 елда ул "Язлар моңы" фестивалендә Гран-при алды.

22 яшьлек оныгым Илнур "Татар кызы" бәйгесен бик матур итеп алып барды.

- Киләчәккә нинди өметләр белән яшисез?

- Исәнлектә-сулыкта, балаларыма үрнәк, кадерле ана, кадерле әби булып яшәргә язсын. Аллаһы Тәгалә Иман һәм зиһен байлыгы, камил акыл бирсен. Раббыбызга шөкер, кызым, улым, оныгым акыллылар, сүземне тыңлыйлар, киләчәктә дә шулай булсын иде.

Яшьләргә шуны әйтәсем килә – һәр эшне вакытында тормышка ашырырга кирәк, иртәгәгә калдырмаска. Гомер бит ул, бер мизгелдәй, бик тиз үтә. Алда ни буласын әйтеп булмый. Үткәненә үкенергә түгел, яшь чакта янып, дөрләп яшәргә тырышыгыз.

Мин үзем бай эчтәлекле, матур тормыш үттем, дип саныйм. Гел хәрәкәттә, халык белән аралашып гомер кичерәм. Бер эштән дә чирканмадым. Хастаханәдә санитар булып та эшләдем, атка атланып, көтү дә көттем.

Үз милләтемә хезмәт итүдән ләззәт табам, телебезне, горефгадәтләребезне саклауга һәм үстерүгә өлешемне кертәм, шөкер. Балаларым һәм туганнарым белән шатланышып, дус булып яшәдек һәм яшибез. Алга таба да шулай булсын.

Татар милләте яшәсен. Без – бай тарихлы горурланырлык халык. Мирасыбызны саклап, аны яшь буыныбызга тапшырыйк. Лаеклы уллар һәм кызлар үстерик!

ОЧУЧЫЛАР ӨСТЕНДӘ ҮТӘ ДӘ ЗУР ҖАВАПЛЫЛЫК ЯТА

Очучы һөнәрендә тирән серлелек һәм хыялый ашкыну көче бар. Кемнәр генә күктәге кошларга сокланып, үзләре дә галәм киңлекләрен кочып иңләргә омтылмаган икән?!
Ләкин очучы булу өчен әле хыялый һәм кыю кеше булу гына да җитми. Аңа куркыныч туган вакытта үз өстенә зур җаваплылык алып, бер мизгелдә хәлиткеч карар кабул итә белү сәләте дә кирәк.

Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ

Иске Ярмәк авылында туып-үскән кешеләр арасында да очучылар барлыгы һәм шуларның берсенең, Бөек Ватан сугышында катнашып, анда батырларча һәлак булуы – безнең өчен горурлык билгесе. Очучларыбызның берсе соңгы еллардагы локаль сугышларда да катнашкан. Ул – Гариф улы Рәҗгать Фәретдинов. Түбәндә аның белән әңгәмәбез.

– Очучы булу өчен кешедән нинди сыйфатлар таләп ителә?

– Моның өчен, иң элек, физик яктан таза һәм исән булырга кирәк. Чөнки очучыдан салкын канлылык, нервлар ныклыгы, төшенкелеккә бирелмичә, авырлыкны җиңә белү таләп ителә.

Очучы булу өчен, физкультура һәм спорт белән шөгыльләнеп, үзеңне чыныктырырга һәм ихтыяр көчен тәрбияләргә кирәк. Без үскәндә яшьләргә патриотик һәм физик тәрбия бирү мәсьәләләренә аеруча зур әһәмият бирелә иде. Шуңа да безнең буын кешеләре көчле һәм таза булып үстеләр. Әлбәттә, авыл хуҗалыгындагы төрле эшләрдә чыныгып үсү дә моңа сәбәпче булгандыр.

Аннан соң, патриотизм белән сугарылган төрле китаплар укып, кинофильмнар карап үскәндә кемнәр генә очучы булырга һәм батырлыклар күрсәтергә хыялланмагандыр ул вакытта! Менә мин дә шундый хыяллар белән үстем һәм морадыма ирешү өчен, үземне чыныктырып, ничек тә шушы һөнәр иясе булу өчен бар көчемә тырыштым.

– Очучыларны әзерләү эше ничек бара?

– Монда: “Өйрәнгәндә авыр булса – яуда җиңел була”, – дигән әйтем бик урынлы. Очучыларны әзерләү училищесында да курсантларны физик яктан тәрбияләү мәсьәләсенә аеруча зур әһәмият бирелә иде. Һавада очрый торган көтелмәгән һәм катлаулы вакыйгалар вакытында үзеңне ничек тотарга һәм аларны ничек хәл итү юлларын тренажёрларда, җирдәге күнегүләр вакытында ныклап

өйрәтәләр. Әлбәттә, һавада нинди хәлләр буласын алдан белеп бетереп булмый. Шуның өчен көтелмәгән очракларда экипаж командиры шәхсән үзе карар кабул итә. Чөнки аңа экипажның һәм пассажирларның язмышын кайгырту белән бергә төялгән йөк өчен дә тулы җаваплылык йөкләнгән.

– Эш дәверендә сезгә Африка илләрендә, сугышлар барган җирләрдә дә булырга туры килгән. Анда булган хәлләрне дә сөйләп үтсәгез иде.

– Һәр сугыш үлем һәм кан коюларга бәйләнгән. Мәсәлән, Анголада ярты ел булганда миңа күпне күрергә туры килде. Анда без сугыш барган җирләргә азык-төлек, дарулар һәм башка кирәк-яраклар ташый идек. Ярый әле, бәхетебезгә, ул вакытта стингерлар кебек кораллар булмады. Ләкин дә һавага күтәрелгәндә яисә төшкәндә аэродром өстеннән читкәрәк тайпылдыңмы – бәреп төшерәләр. Шуның өчен менгәндә дә, төшкәндә дә без тик аэродром өстендә генә, воронка яисә спираль рәвешендәге хәрәкәтләр ясап, очып менә һәм төшә идек.

Аннан соң, чүлдәге һава шартларында очуның көтелмәгән табигый кыенлыклары да бар. Мәсәлән, чалт аяз, кояшлы көндә дә көтмәгәндә ком бураны күтәрелсә, ярты метрдан бернәрсә күреп булмый. Мондый очракта очучы осталыгына, тупланган тәҗрибәгә һәм интуициягә генә таянып эш итәргә туры килә.

– Сезгә хәлиткеч вакытта, алдан күреп, куркыныч һәм тәвәккәл адымнар ясарга туры килгәне булдымы?

– Булды. Мәсәлән, бервакыт җиргә утырырга җыенган вакытта бер тәгәрмәчнең ачылмаганы беленде. Мондый очракта мин, экипаж командиры буларак, аңлы рәвештә бетон полосадан читтәге тигессез кырга бер тәгәрмәчкә генә утырырга карар кабул иттем. Шундагы дыңгырчыкта икенче тәгәрмәч тә ачылды, һәм без һәлакәттән котылдык. Бу сирәк кулланыла торган куркыныч һәм тәвәккәл адым булса да, ул катастрофадан котылу өчен бердәнбер чара иде.

Тагын бер вакыйганы телгә аласым

килә. Очып күтәрелгән вакытта кинәт май күрсәткеченең кискен рәвештә түбән төшүен күрдем. Иллюминатордан карасам, һавада мотордан май тасмасы сузылган иде. Тиз рәвештә кырга утырырга туры килде. Анда май шлангасының өзелгәнлеге беленде. Әле ярый якында гына эшкә яраксыз самолётлар тупланган база бар иде. Шуннан кирәкле шланг табып, шуны куйдык һәм кирәк җиргә очтык.

– Самолётларны бәреп төшергән очраклар булдымы?

– Әйе. Бер самолётны бәреп төшергәч, аның очучылары мина кырлары аша аэродромга таба юнәләләр. Башта юл күрсәтүче негр минада шартлап үлә. Аннан соң экипаж командиры яралана, һәм ул да һәлак була, чөнки вакытында ярдәм күрсәтеп, операция ясау өчен мөмкинлекләр юк иде.

– Сез төрле очкычларда очкансыз. Алар арасында иң зур һәм иң катлаулы булганнары да бар. Аларны үзләштерү ничек барды?

– Мин сигез төр очкычны үзләштердем һәм аларда очтым. Һәркайсысын үзләштергәндә дә яңабаштан укырга һәм тәҗрибә тупларга туры килде. Моның өстенә, даими рәвештә очучыларның квалификациясен күтәрү курсларында укыдым.

Иң элек, мин АН-2 очкычында икенче пилот булып эшли башладым һәм иң ахырда хезмәтемне АН-12 очкычында тәмамладым. Эшләү дәверендә ЯК-18, АН-2, ИЛ-14, АН-24, АН-26, АН-74, АН-12 маркалы очкычларны үзләштердем һәм аларда очтым.

1981 елдан башлап, Гражданнар Авиациясенең Коми идарәсендәге төрле җитәкчелек вазыйфаларын башкардым. Хезмәт ветераны булып пенсиягә чыктым. Эшләү дәверендә командование исеменнән кырыклап мактаунамә, рәхмәт хатлары һәм “Отличник ВГРФ” исеме бирелде.

– Сез эскадрилья командиры һәм җитәкче булып та эшләгәнсез. Мондый дәрәҗәгә ничек ирешә алдыгыз?

– Монда махсус комиссия, кешенең эш нәтиҗәләренә, эш тәҗрибәсенә һәм төрле күрсәткечләргә таянып, үз карарын кабул итә. Аннан соң ул югары оешмалар һәм командование тарафыннан раслана.

Бүгенге көндә Гариф улы Рәҗгать Фәретдинов туып-үскән Иске Ярмәк авылында яши. Ул – ихластан дингә бирелгән актив мәчет карты. Җитмеш



җиде яшендә дә төз һәм таза гәүдәле. Төпле фикерле, аз һәм туры сүзле булса да, ачык йөзле, көр күңелле һәм актив тормыш позициясендә тора.

Аңардагы сирәк очрый торган тыйнаклык һәм киң күңеллелек – искиткеч матур күренеш. Сөйләмендә, үз-үзен тотышында да бай тормыш тәҗрибәсе, рухи ныклык һәм матур кешелек сыйфатлары ачык күренәләр.

Аның белән аралашканда ирексездән: “Менә нинди булырга тиеш ул – олы тормыш юлын үткән һәм ихласлы мәчет карты дип саналырлык кеше!” – дип уйлап куясың.

ВЫПОЛНЯТЬ СВОЙ ДОЛГ, ПРЕОДОЛЕВАЯ ЧУВСТВО СТРАХА НА ВОЙНЕ, – ЭТО ПОДВИГ

Во второй половине XX века поколению мальчишек нашей страны пришлось воевать в разных горячих точках и в различных странах, где проливалась кровь. Но это особо не афишировалось. Это был пик разгара холодной войны между мировыми державами – социалистическими и капиталистическими.

Афганистан – одна из самых кровавых точек на планете Земля. На протяжении столетий здесь шли, да и сейчас идут нескончаемые войны. Поэтому цивилизация в своем развитии там застыла на этапе феодализма.

Во все времена Афганистан был стратегически важной зоной на юго-востоке Азии и представлял огромный интерес для империалистических захватчиков. Но, однако, на всем протяжении его истории Афганистан не смог завоевать никто.

Фарид ШИРИЯЗДАНОВ

Балачагында һәм яшүсмер елларында бик күп авырлыклар кичерсә дә, Миңнурый Зәки кызы, яраткан егете Әкъдәс Төхвәтуллинга тормышка чыккач, бик бәхетле гомер кичерә.

Ул гомере буе Шенталыдагы азык-төлек комбинатында мастер булып эшләп, зур дәрәҗәләргә ирешкән. Бүгенге көндә Әкъдәс абый якты дөньяда юк инде. Гыйззиҗамал әби белән Мәрьям апаның да бакыйлыкка күчүләренә күп еллар үтеп киткән.

Ләкин Миңнурый апа ялгыз түгел, Себер киңлекләрендә хезмәт куеп, лаеклы ялга чыккач, бирегә кайткан кызы Әнүзә апа белән кияве Мәҗит абый үзен хөрмәтләп карыйлар. Мәҗит абый гомере буе машина йөртүче булган, "Россиянең дәрәҗәле транспорт эшчесе" исеменә ия. Ә Әнүзә апа диспетчер булып хезмәт иткән.

Күптән түгел Миңнурый апа туксан яшьлек юбилеен билгеләп үткән. Аны зурлап, Себердә гомер итүче улы Ринат, килене Гөлчәчәк, кызлары Камилә кунакка кайтканнар. Һәм барлык оныклары, туганнары тәбрик иткәннәр.

Әйе, Миңнурый Зәки кызы бик бәхетле картлык гомере кичерә. Ул:

- Без, әти-әниләребез һәм башка кешеләр күргәннәрне Раббыбыз башка беркемгә дә күрсәтмәсен, ил-көн тыныч булып, гөнаһсыз сабыйлар туа торсын, җир йөзендә шатлыклы яшәү дәвам итсен иде, - дип, изге догалар кылып яши.

ЗАПОМНИВШИЕСЯ СЕЛА

Однажды мне попалась на глаза книга индийского этнографа М.Н. Шриниваса «Запомнившаяся деревня», в которой описывалась южноиндийская деревня, где автор долгое время жил, изучая культуру и быт местного населения. Читая эту книгу, погружаешься в деревенский мир, не просто узнаешь, но и чувствуешь особенности жизни и быта местного населения.

Михаил Владиславович КРЖИЖЕВСКИЙ

Сельский мир нашего многонационального края не менее самобытен и интересен. Выделить какое-то одно сельское поселение из всех посещенных во время многочисленных этнографических исследований я бы, наверное, не смог – каждое запомнилось по-своему. История и современность татарских сел нашей области хорошо описаны в фундаментальном труде «Татары Самарского края». В этой статье я предлагаю просто обратить внимание на некоторые особенности.

Алькино – красивое татарское село, раскинувшееся на востоке нашего края, почти на границе с Оренбургской областью. Впервые я посетил его осенью, когда уже многие деревья надели ярко-золотистые и огненно-красные наряды, но было еще тепло – чувствовалось дыхание ушедшего лета. Еще гуляют по улицам домашние животные: вот идут вразвалочку гуси, вот подал голос петух, а там лениво смотрит вокруг корова. Запомнились добротные дома с сараями, амбарами, теплицами, мечети и медресе, прекрасный вид с возвышенности на село и окрестности. Запомнился небольшой концерт, который организовал местный творческий коллектив. И, конечно, гостеприимство местных жителей, которое сегодня уже редко встречается в городах. Потом была поездка в это село на сельский Сабантуй федерального значения. Вспоминая это, хочется верить, что все пандемии скоро уйдут в прошлое, и вновь засияет яркими красками самобытная праздничная культура.

Первое башкирское поселение, в котором мне довелось побывать, находится на Урале – это село Бажикаево Аргаяшского района Челябинской области. В этих местах немало лесных массивов, поэтому местные башкиры издавна строят свои дома из дерева. Запечатлелась также в памяти высокая березовая роща на здешнем кладбище. Потом были башкирские села Баймакского района Республики Башкортостан – Хасаново, Куянтаево, Тавлыкаево. В эти края я попал в составе комплексной экспедиции, организованной учеными Башкортостана. Эти края уже напоминают места, в которых живут самарские башкиры, – кругом привольные степи, многие дома построены из саманного кирпича…

А затем начались поездки по башкирским поселениям Самарской области, каждое из них также запомнилось как что-то яркое, во многом неповторимое…

Башкирское село Таш-Кустьяново я посещал много раз, в том числе поздней осенью, когда кругом лежал снег, но в основном, конечно, летом – обычно в это время у нас проводятся этнографические исследования. Саманные дома, традиционные предметы быта, старинное кладбище… Тоже запомнились картины с домашними животны-

ми. Скачет всадник верхом на лошади, напоминая о кочевом прошлом башкирского народа. Неторопливо бредут овцы – их всегда было много в хозяйствах самарских башкир, не случайно в местном диалекте много слов, характеризующих овец разного возраста. Волшебным звуком курая, сочетанием старых и новых хозяйственных построек и обилием домашней птицы запомнились посещения башкирского поселка Кочкиновка пару десятков лет назад… И везде – в Челябинской области, в Башкортостане, в селах самарских башкир – везде традиционное сельское гостеприимство, которое когда-то так покорило Льва Николаевича Толстого.

В некоторые села я приезжал со студентами – учил их работать «в поле», знакомиться с особенностями национальной культуры непосредственно на месте, смотря на традиционные жилые хозяйственные постройки, старинные предметы быта и разговаривая с сельчанами. И студентов – представителей современной молодежи – так приятно удивляло и очаровало местное гостеприимство. Вот бы и в городе так, а то замкнулись многие в своем мирке, и не достучишься. Не мог я не обратить внимания и на то, как студенты фотографируют «экзотических» животных: тех же коров, коз, овец, гусей… Бывало, что путали гусей и уток, овец и коз. Почему? Не только потому, что выросли исключительно в городской местности, не имея бабушек и других близких родственников в селе. Дело еще и в том, что в самих селах стало значительно меньше домашних животных, чем было, скажем, в восьмидесятые годы прошлого века. Трудно содержать их, хлопотно и затратно, а работы часто нет, вот и едет молодежь в город, а старикам это уже не под силу. Так что, пользуясь случаем, хочется сказать спасибо тем, кто возрождает село, предоставляет возможность работать местным жителям, поднимает животноводство. Животноводство издавна играет большую роль в хозяйстве и культуре татар, башкир и других народов края. Хотелось бы, чтобы овец, коз, гусей и других домашних животных мы видели не только в зоопарках, но, в первую очередь, в селах.

ИДЕЛ БУЕ ШВЕЙЦАРИЯСЕ

Әгәр элек Самарга туристлар дөньяда бердәнбер вертикаль урнаштырылган «Союз-2» космик ракетасын һәм «Сталин бункеры»н күрү өчен килсәләр, бүген кунаклар күбрәк Идел яр буендагы пляжларга, ягъни курорт зонасына тартыла. Ә анда аларны кояш, һава һәм су гына түгел, төрле фестивальләр, күргәзмәләр, гамәли иҗат осталарының шәһәрчекләре көтә. Моннан тыш, Самар өлкәсенең табигате бик үзенчәлекле һәм искиткеч гүзәл. Төбәк территориясендә өч йөздән артык табигать һәйкәле бар. Безнең өлкәгә кунакка килгән туристлар, Һичшиксез, Жигули тауларын, Рачей тайгасын, Таш касәне күреп китәргә тиеш, минемчә.

Эльмира Сәйфуллина

Смолькино Эко Вилладж

Бөтен дөньяда да экологик туризм популярлаша бара. Әмма табигать кочагында ял итәргә яратучыларның барысы да шәһәр тормышы уңайлыклары белән аерылышырга әзер түгел. Нәкъ менә шундыйлар өчен “глэмпинг”лар уйлап табылган да инде. Икенче сүз белән әйткәндә, “гламурный” кемпинглар, уңайлыклары булган палаткалар була инде ул. Мондый глэмпинглар Антарктикада, Хабаровск краенда, Кольский ярымутравында бар. Соңгы елларда Европада да йөзләгән шундый комплекслар булдырылган, ә менә Россиядә туризмның бу төре әлегә туу стадиясендә генә.

Самар өлкәсендә генә түгел, Идел буе федераль округында да бердәнбер глэмпинг 2019 елда Сызран районының Смолькино авылы янында ачылган. Бу - өлкәбездә экотуризмны үстерү һәм авыл хуҗалыгын торгызу юнәлешләрен берләштерүче яңа бизнес-проект. Исеме дә заманча - «Смолькино Эко Вилладж». Глэмпинг тиешле дәрәҗәсенә җитеп бетмәгән әле, әлегә үсештә. Биредә булачак алмагач бакчасына нигез салынып, биш йөзләп үсенте утыртылган, шәһәр ыгы-зыгысыннан туеп, авылда ял итәргә теләүчеләр өчен гөмбәзе үтәкүренмәле булган чатырлар төзелгән, мәйданы да шактый зур - 28 квадрат метрда ял итү, аш-су бүлмәләре, бәдрәф, душ, хәтта джакузи һәм кондиционер бар. Диварлары ике катлы тент арасына синтепон сырып эшләнгән, идәннәре дә җылытыла. Үтәкүренмәле стена аша җәен дә, кышын да табигать матурлыгына, йолдызлар җемелдәвенә сокланырга мөмкин. Глэмпинглар ел әйләнәсе файдалану өчен яраклы һәм әйләнә-тирә мохит өчен экологик яктан куркынычсыз итеп ясалганнар. Биредә утызлап гөмбәз урнаштыру планлаштырыла. Якын арада ресторан һәм спа-зона да ачылачак икән.

“Җирле халык, тулаем алганда, яңа күршеләрне уңай кабул итте. Глэмпинг - район һәм өлкә абруе гына түгел, ул җирле халыкка өстәмә эш урыннары булдырачак, яшьләрне авылда калырга җәлеп итәчәк. Ә элек–элек биредәге халык нарат сумаласыннан дегет, канифоль, скипидар эшләп көн күргән. Хәзер дә урмандагы күпчелек нарат көпшәләрендә сумала җыю өчен ясалган конуссыман эзләр сакланган.

Әлеге проект Смолькино авылына газ үткәрү сәбәпчесе дә булды бит әле. Хәзерге вакытта газ кертү проекты әзер, эш башлануын көтәбез", - дип сөйли проект җитәкчесе Алексей Зиновьев.

Глэмпинглар, гадәттә, табигате уникаль булган урыннарда төзелә. Смолькино авылы нәкъ шундый урында урнашкан - хәзер дә анда гыйффәтле табигать почмаклары сакланып килә. Бу авыл, тарихи-мәдәни һәм табигый мирас иясе буларак, «Россиянең иң матур авыллары» ассоциациясе әгъзасы булырга лаеклы. Бу җирләрдә Рачей тайгасы, Җиде чишмә, Моховой һәм Узилово сазлыклары, Рачей кыялары кебек табигать һәйкәлләре урнашкан. «Смолькино Эко Вилладж» әкияти матур Чәй күле ярында утыра. Күлнең өсте, көзге кебек, тигез, суы үтәкүренмәле һәм салкынча. Яр буйларында гел тынлык, чөнки тирә-ягында төз каеннар һәм наратлар үсә. Ә Чәй күле дип аталуының сере – суы куе чәй төсендә булганлыктан. Ул беркайчан да туңмый һәм исләнми, анда бернинди микроорганизмнар да яшәми. Ә менә глэмпингта ял итүчеләр дә, авыл халкы да монда рәхәтләнеп су коена. Балык тотарга яратучылар өчен ясалма ике күл булдырылачак. Анда форель балыгын үрчетәчәкләр. Тоткан балыкны шунда ук кыздырып ашарга да мөмкин булачак.

Глэмпинг янындагы табигать Самар өлкәсенең башка урыннарыннан ныклы аерылып тора. Бу - Смолькино авылы тирәсендәге серле таш скульптуралар, кыялар һәм лабиринтлар паркын барлыкка китерүче комташ калдыклары һәм кантарлары, урыны белән хәтта япон таш бакчаларын хәтерләткән лабиринтлар (Рачей лабиринтлары). Әлеге табигать табышмагы туристларны фантастик дөньяга яисә Карелия, Шотландия тайгаларына күчерүче әкияти көчкә ия. Кыяларның күпчелеге шомартылган яки бөкләнгән формада булуы күзгә ташлана. Аларның кайберләре тишекле, мүк һәм лишайник белән капланган гаять зур сыр яисә Ай өстен хәтерләтә. Икенчеләре ташта катып калган хайваннарга охшаган. Ташларның кабатланмас формалары өчен җирле халык һәм туристлар күп кенә табигый скульптураларны

"Уйлаучы" (Мыслитель), "Ладья", "Таш айгыр" (Каменный Конь), "Сугышчы" (Воин), "Ташбака" (Черепаха), "Бегемот", "Рачейский Сфинкс" дип атаганнар.

Моховое һәм Узилово сазлыклары да - Самар өлкәсенең уникаль урыннары. Бу - тундра даласы җәелеп яткан заманнардан калган бозлык чоры эзләре. Сазлыкның өслеге үрелеп үскән мүк җиләге, үлән сабаклары һәм тамырларыннан барлыкка килгән түшәк белән капланган. Биредә Россиянең урта полосасы өчен бөтенләй дә ят булган мүк җиләген (клюква) һәм кызыл көртмәлекне (брусника) күрергә мөмкин. Шулай ук мондагы урманнарда гөмбә һәм җиләк искиткеч күп.

Смолькино тирәсендәге истәлекле урыннар белән танышу өчен бер атна вакыт та җитмәс, мөгаен. Биредә 2 - 5 сәгатькә сузылган биш туристик маршрут оештырылган. Ял итүчеләр бу юлларны квадроцикларга атланып үтәләр. Ә кышын туристлар снегоходта яисә чаңгыда йөри.

Вертолетка

Шәһәребезнең тагын бер танылган урыны - легендар атаман Богдан Барбоша исемен йөрткән алан. 2007 елга кадәр Самарның бу бик матур урыны революционер Михаил Фрунзе аланы дип атала иде. Риваятьләргә караганда, Самар Җәясенең куе урманнарында Атаман Богдан Барбоша җитәкчелегендәге казак отрядлары хөкем иткән. Алар Иделдән Уралга кадәр җәелеп яткан җирләрне Россия империясенә кушуда катнашканнар, Алтын Урда гаскәрләре белән көрәшкәннәр.

Ә инде дөньялар тынычлангач, бу аланда данлыклы кымыз шифаханәсе ачып җибәрәләр. Сәламәтлегеен ныгыту өчен Идел буе Швейцариясе дип аталган бу урынга халык бөтен Россиядән агыла башлый.

Барбоша аланында яшәгән сәнәгатьче Иван Соколовның ике йорты әлегәчә сакланган, һәм алар бүгеен дә Чкалов исемендәге шифаханә корпуслары булып хезмәт итәләр. Йөрәк авыруларын дәвалау белән шөгыльләнүче шифаханә хезмәткәрләре легендар пациент Алексей Маресьевны искә алырга яраталар. Язучы Борис Полевойның «Повесть о настоящем человеке» романы герое, ике аягын кистергәч, биредә реабилитация уза, протезлар ярдәмендә яңадан йөрергә өйрәнә. Алай гына да түгел, ул кабат самолет штурвалын кулына ала һәм дошманга каршы көрәшен дәвам итә. Аркадий Гайдарның «Тимур һәм аның командасы» әсәре буенча фильм да шушында төшерелгән.

Пристаньнан башлап, Идел буе микрорайонына кадәрге Барбоша аланы дип аталган җирләр - Михаил Фрунзе, Аркадий Гайдар, Алексей Маресьев кебек легендар геройларыбызның исемнәре белән

дә яктыртылган бай тарихлы урын ул. Революциядән соң биредә пионер лагерьлары, хөкүмәт башлыклары өчен дачалар, ә гади халык өчен турбазалар төзелә.

Самарның Управленческий бистәсендәге "Вертолетка" дип аталган урында күпләр булганы бардыр, ә менә аның ни өчен шулай аталганын белүчеләр аздыр, минемчә. Үткән гасырның 30 - 40нчы елларында әлеге мәйданчык, чыннын да, вертолет утырту урыны булып хезмәт иткән. Ул ракета двигательләре төзү заводының генераль конструкторы Николай Кузнецов вертолетын утырту өчен кирәк булган. Үзгәртеп кору чорыннан башлап, әлеге урын вертолет мәйданчыгы буларак кулланылмый, ә күбрәк Самар халкының яраткан ял итү урынына әверелә башлый. Шулай итеп, ул 2000нче еллар башында Идел буе гүзәллеген күзәтү мәйданчыгы итеп җиһазландырыла. Аннан «Самар Җәясе» милли паркы, Идел елгасы, Самар шәһәре, Жигули таулары, Красная Глинка һәм Управленческий бистәләре ачык күренә. Монда туристлар саф һава сулап, искиткеч табигать күренешләренә сокланып утырсын өчен эскәмияләр куелган һәм янәшәдә генә кафе да бар.

Юлыбызны дәвам итеп, табигать һәйкәле булып саналган Волжский бистәсенә юнәләбез. Сок елгасы Иделгә килеп кушылган урында мәйданы 13,7 гектар булган Царев Курган урнашкан. 1391 елның июнендә Тохтамышны җиңгән Тамерлан (Тимур) шунда туктала. 1722 елның язында Идел буйлап Персиягә сәфәр иткән патша Петр I Курган янында ял итеп ала. 1824 елда император Александр I дә, тауга менеп, Идел буе гүзәллегенә сокланган. Шулай ук Курган тарихы Степан Разин белән дә бәйле. Имеш, шушы тау битендә ул ике чиләк алтын күмеп калдырган. Кем белә бит, бәлки, шулайдыр да.

Советлар чорында Сызрань тимер юлы күперен, Куйбышев ГЭСын төзү, юллар салу өчен, Курганны казып, известняк чыгара башлыйлар. Нәтиҗәдә аның биеклеге бик нык үзгәрә. Шулай булуга карамастан, Царев Курган фото-туристларның иң яраткан урыннарының берсе. Чөнки тау башыннан Идел елгасы, Ширяево авылы, Жигули капкасы дип аталган Тип-Тяв һәм Күкерт тавы арасы бик яхшы күренеп тора.

Мондагы матурлыкларга сокланып, фотога төшеп туйганнан соң, сәфәребезне дәвам итәбез. Җәйге кызудан һәм шәһәр ыгы-зыгысыннан туйган, әмма ерак сәфәр кылырга теләмәгән кешеләр өчен күл буенда, нарат урманы эчендә урнашкан "Русская охота" кунакханәсе менә дигән ял урыны булыр. Биредә ирләргә аучылык, балык тоту белән шөгыльләнү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Шулай ук балаларга - зоопарк, хатын-кызларга – мунча һәм бассейн, яшьләргә атка атланып йөрү, бильярд, теннис, волейбол, баскетбол, футбол кебек спорт чаралары, күңел ачу программалары тәкъдим ителә. Ә кышын ял итүчеләр чаңгыда йөриләр, таудан шуалар, ә, арыгач, ачык һавада самавыр тирәсенә җыелышып, үлән чәе эчеп алалар. Кыскасы, елның теләсә кайсы вакытында «Рус охотасы» сезне иң кадерле кунаклар кебек каршы алачак.

Управленческий бистәсендә урнашкан "Әкият" рестораны да кунакларны колач җәеп каршы ала. Тышкы яктан бернинди дә үзенчәлекле булмаган бина эчендә

чын әкият яши икән! Ресторан залына аяк басу белән көндәлек мәшәкатьләр, ару-талулар онытылып, андагы матурлыктан башлар әйләнеп китә. Мәрмәр, җемелдәп торган Сваровски ташлары белән бизәлгән залны, һавадай җиңел тәрәзә пәрдәләрен һәм классика стилендәге җиһазларны күреп, патша сараена килеп эләккәндәй буласың. Мондагы матурлыкны сүз белән генә әйтеп аңлатырлык түгел, бу әкиятне үз күзләрең белән күрергә кирәк. Ресторан тәкъдим иткән ашамлыклар да искиткеч сыйфатлы һәм тәмле. Ә җылы вакытта җәйге кафеда ял итәргә мөмкин. Биредә дә кечкенә кунаклар өчен балалар шәһәрчеге һәм зоопарк бар.

Жигули таулары (Жигули тыюлыгы), Таш касә

Күп миллионлы Самар һәм Тольятти сәнәгать-индустриаль агломерациясенең нәкъ үзәгендә, Идел елгасының зур борылышы һәм Уса елгасы белән кушылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән ярымутрауда Иван Спрыгин исемендәге Жигули тыюлыгы (Жигулевский заповедник) урнашкан. Тыюлыкта килеп чыгышы һәм төзелеше буенча уникаль булып саналган Жигули таулары, урман-далалы табигый һәм мәдәни ландшафтлар, Идел һәм Уса елгалары үзәннәре җәелеп ята. Андагы катнаш урманнарда, болын далаларда үскән үсемлекләр һәм җәнлек-бөҗәкләр төрлелеге белән аерылып тора. Тауларның уникаль экосистемасы, кеше аягы басмаган нарат урманнары һәм таш далалары, сфаган сазлыклары, су асты имәнлекләре һәм култыксыман болыннар бөтен дөнья галимнәрен кызыксындыра. Шушы төбәкнең искиткеч уникаль табигатен өйрәнү һәм саклап калу максаты белән 1927 елда совет ботанигы Иван Спрыгин инициативасы буенча Жигули тыюлыгы булдырылган да инде. Кызганычка, ачык һавадагы әлеге уникаль лаборатория XX гасыр дәвамында берничә тапкыр ябыла. Тик 1966 елда гына ул Жигули дәүләт тыюлыгы буларак тулысынча раслана.

Бу якларның гаҗәеп саф һавасы, сихри табигате экотуризм сөючеләрне җәлеп итә. Елның кайсы фасылына карамастан, Жигули тыюлыгында туристлар сукмагы буш тормый. Табигать бөтенлеген бозмыйча гына, үсемлекләр, хайваннар, кошлар, бөҗәкләр турында белем тупларга, гомумән, гыйффәтле матурлык белән ләззәтләнергә теләүчеләр

өчен тыюлык буенча ике туристик маршрут төзелгән. Беренчесе - Стрельная тавына сәяхәт. Бу Жигули тавының 351 метрлы иң югары нокталарының берсе. Әлеге урын Самар өлкәсенең иң матур табигатьле истәлекле урыннарының берсе булып санала. “Юл башында биек дивар сыман тыгыз урман үсә, тора-бара зур булмаган аланнар күренгәли башлый. Күләгәле яшел тоннель буйлап текә сукмактан күтәрелгән туристларны яктылык һәм саф һава дулкыны чолгап ала. Мондагы иркенлек, яшеллек, зәңгәр күк йөзе һәм су өстендә уйнаган кояш нурлары һәркемне таң калдыра! Моннан караганда Идел буйлап йөзеп баручы пассажир теплоходлары, танкерлар һәм сухогрузлар уенчык кебек кенә күренә”, - дип хис-кичерешләре белән ур-

таклашалар туристлар. Ләкин Стрельная тавы биеклеге буенча икенче урында гына тора, ә Жигули тауларының иң биек ноктасы булып 381 метр биеклектәге Наблюдатель (Күзәтүче) тавы санала. Риваятьләргә караганда, XVI-XVII гасырларда Стрельная тавы «жигулевская вольница» буларак билгеле булган качкын крестьяннарның күзәтү пунктлары итеп файдаланылган. Алар Идел аръягында яшәгән Ногайларны, шулай ук Идел буйлап үтүче сәүдә көймәләрен талау белән шөгыльләнгәннәр. Хәзерге вакытта Стрельная тавы башында туристлар өчен күзәтү мәйданчыгы оештырылган. Кагыйдә буенча, әлеге урыннарга турист төркемнәре һәм тыюлык дирекциясе рөхсәте буенча гына күтәрелергә рөхсәт ителә. Тау башы

биредәге үсемлекләрне һәм тереклекне таптаудан саклаучы тимер баскыч белән җиһазландырылган. Тауга кадәр бары тик шәхси автомобильгә яисә экскурсия автобусына утырып барырга мөмкин. Автомобильне махсус тукталышта калдырып, маршрутны җәяүләп дәвам итәргә кирәк булачак. Маршрут буйлап истәлекле урыннар турында мәгълүмат бирүче стендлар, ял итеп алу өчен утыргычлар урнаштырылган. Тукталышта уңайлы бәдрәф тә бар.

Жигули тыюлыгына бару бәхетенә ирешкән кешеләр Каменная Чашаны (Таш касәне) күрмичә кайтмый. Каменная Чаша Ширяев чокыры, башка вак чокырлар белән кушылып, киңәйгән урында урнашкан. Һәр яктан биек тау сыртлары белән әйләндереп алынган чокыр гаять зур казан яки таш касәне хәтерләтә. Табигатьнең матурлыгы һәм аулак урын булуы белән ул туристлар тарафыннан бик югары бәяләнә. Каменная Чаша янына бару өчен көнбатыш яктан 2,2 километр текә тауга менәргә яисә көнчыгыш яктан, Ширяево авылы ягыннан 10 километр юл үтәргә кирәк. Озын юлны сайлаучыларга бормалы-бормалы Ширяев чокыры буйлап 4 сәгать чамасы барырга туры килә. Ә кыска юлдан - Кояшлы Алан аша куе урман һәм таулар белән уратып алынган тар сукмак буйлап текә тау сыртына менеп җиткәч, шундый ук озын һәм текә сукмак буйлап төшәргә дә туры киләчәк. Барган саен, урман куера, әйләнә-тирәдәге биек үләннәр, чәчәкләр төрлелеге арта бара. Монда кыңгырау чәчәкләренең сирәк очрый торганнарын да күрергә була. Бу гүзәллек арасында үзеңне әкияттәге кебек хис итәсең, чәчәкләрнең моңлы «бәллүр» шалтыратуларын ишеткән сыман булып тоела. Таш Касә тыюлыкта урнашканга күрә, монда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белергә кирәк. Биредә лагерь оештырырга, учак ягарга, сукмактан чыгарга, чүп-чар ташларга ярамый. Бу тылсымлы урында өч чишмә бар. Әмма төп сукмак төзекләндерелгән беренче чыганакка илтә. Ул «Изге Николай Чудотворец чыганагы» дип атала. Бу чишмә суы сәламәтлек һәм озын гомер бирә, дип санала. Шуңа күрә чыганакка төрле дин кешеләре килә. Изге чишмә суы белән коену өчен шунда ук махсус бина да бар. Шунысы кызык, су температурасы җәен дә, кышын да плюс биш градус тәшкил итә.

Валерий Грушин исемендәге бард җыры фестиваленең беренчесе, хәзерге кебек, Мастрюков күлләрендә түгел, ә нәкъ менә Каменная Чаша янында узуын белүчеләр бик аз, минемчә. Ул 1968 елның 28 - 29 сентябрендә турист җырларын пропагандалау, иң яхшы башкаручыларны ачыклау максатында, 1967 елда Уда елгасында суга батучыларны коткарганда үзе батып үлгән студент Валерий Грушин истәлегенә уздырыла.

Каменная Чаша - җәяүләләр өчен дә, атлы һәм велопоходлар өчен дә бик уңайлы урын. Инде май башында ук юллар кибә һәм анда гади велосипедта да җиңел генә узарга мөмкин. Тыюлык җирендә ял итү өчен билетны Ширяево авылында урнашкан милли парк кассасында алдан ук сатып алырга кирәк.

Бу әкияти табигатьле Жигули тыюлыгының символы булып бурсык санала. Бахилов Аланы авылында бу сөйкемле җәнләкләр өчен хәтта «Бурсыклар шәһәрчеге» дип аталган кечкенә генә питомник та бар. Дөрес, анда хәзергә бары тик өч кенә бурсык яши - Даша, Маша һәм Борис Михайлович. Шулай булуына карамастан, туристлар бу җәнләкләрнең тормышын сәгатьләр буе күзәтергә дә әзер. «Бурсыклар шәһәрчеге» Жигули тыюлыгы идарәсе бинасы артында ук урнашкан. Шулай ук тыюлыкның административ бинасында туган

якның табигате белән кызыксынучы туристлар өчен тагын бер мавыктыргыч урын бар. Музейда Россиянең төрле төбәкләреннән җыелган 200гә якын тау токымнары үрнәкләре һәм минераллар коллекциясе, тыюлык хезмәткәрләре тарафыннан экспедицияләрдә җыелган палеозой һәм мезозой ташлыклары, төрле кош оялары, бөҗәкләрнең сирәк төрләрен туплаган күргәзмәләр бар. Музей эш көннәрендә иртәнге сәгать сигездән кичке сәгать дүрткә кадәр эшли.

Дөньядагы коронавирус пандемиясен исәпкә алсак, якын арада эко-туризмга ихтыяҗ зур булачак, минемчә. Чөнки чит ил сәфәрләре билгесез вакытка кадәр тыелган. Ә яшьләр инде хәзер үк табигать кочагында ял итүне чит ил пляжларындагы ялдан өстенрәк күрәләр. Шуңа күрә, әйдәгез, исәнлегебезне куркыныч астына куймыйк, туган ягыбызның табигатен өйрәник. Безнең өлкәдә уңайлы ял итү өчен искиткеч матур табигатьле урыннар күп.

НАПОМНИЛ О ВЕЛИКОМ НАСЛЕДИИ ТЮРКОВ

В настоящее время в странах Средней Азии, особенно в Казахстане и в Турции прилагают много усилий для возрождения истинной истории тюрков, которые сыграли огромную роль в процессе эволюционного развития многих стран и народов, населяющих Землю.

Фарид ШИРИЯЗДАНОВ

История тюрков загадочна и многогранна. Она всегда волновала и восхищала умы ученых историков в мировом масштабе. Сейчас правдивая тюркская история постепенно занимает свои истинные позиции. Например, в Канаде недавно была издана книга об истории Золотой Орды – государства тюрков, которое в свое время охватывало огромные территории Евразийского континента и в чреве которой зарождались и получили развитие многие современные государства, в том числе и Россия. Написана она учеными с мировыми именами.

Сейчас во всем мире с восхищением воспринимается и многосерийный фильм «Великолепный век», созданный турецкими кинематографистами, где показаны события, происходившие в Османской империи, которая на протяжении шести веков господствовала на трех континентах – в Европе, Азии, а также на севере Африки.

В эпоху правления султана Сулеймана (1520–1566 гг.) Османская империя достигла пика своего могущества и процветания. Город Стамбул, столица империи, тогда был одним из маяков Старого Света как в военно-политическом, так и в экономическом и культурном планах. Этот период был ознаменован и взлетом интеллектуальной мысли, развитием искусств и художественного творчества, в том числе возведением больших султанских мечетей.

Но наиболее важным являлось то, что султан контролировал всю торговлю: водные торговые пути от Индийского океана через Красное море и Персидский залив, а также сухопутные торговые пути, проходящие через весь арабский мир и доходящие до Средиземного моря и в страны Западной Европы.

В фильме «Великолепный век» удачно показаны основные моменты экономической, культурной и интеллектуальной жизни Османской империи, связанные с мусульманским менталитетом.

Этот фильм дает возможность понять сущность событий, происходивших в многоязычной и много конфессиональной Османской империи, и суть структуры ее правления.

Османская империя, владевшая Средиземноморьем, Северной Африкой, Балканами, странами Ближнего Востока и побережьем Черного моря, по праву может считаться наследницей Римской и Византийской империй, а также Арабского халифата.

Система политического строя и история Османской империи всегда приковывали внимание ученых историков и подвергались глубокому анализу. При этом многие считали ее абсолютной монархией и неограниченной деспотией.

На самом же деле султан не мог переступать рамки коранического

закона – шариата. Власть султана была основана на законе и правосудии. Поэтому образ султана Сулеймана Великолепного воплощал в себе достоинство, щедрость и справедливость повелителя. На нем также лежала большая ответственность – заботиться о своих подданных и защищать их.

Широкие полномочия султана были делегированы и его наместникам на местах, а в центре государства – великому визирю и другим членам имперского Дивана (парламента).

На провинциальном уровне тоже происходило тщательное разграничение властей, значительная часть которых были делегированы военным правителям, беям и пашам.

При этом разделение полномочий между наместниками позволяло султану сохранять контроль над своими подчиненными и оставаться на вершине власти. Все чиновники на местах находились во власти повелителя, и они не могли составлять противовес всесильной власти султана.

Султан, повелитель империи, воплощал в себе саму суть централизованного государства. Он приказывал и судил, пользуясь абсолютной властью, ограниченной только его подчинением исламским канонам.

При султане имелся орган, принимающий его решения к исполнению, называемый Диваном. Обычно сам султан не присутствовал на его заседаниях, но мог незримо следить за тем, что там происходит.

Диван рассматривал все вопросы, касающиеся войны и мира, хода военных действий, управления государством и финансами. Он играл и роль высшего органа правосудия. Те, кто чувствовал себя ущемленным в правах, могли обратиться туда с петицией или ходатайством.

Султан Сулейман вошел в историю и как Сулейман Кануни (Законодатель) и Сулейман Справедливый. В процессе законотворчества он ссылался также на обычаи и на древнее право завоеванных народов (адаты), то есть обычное право (от слова обычай). Это позволяло избежать волнений среди завоеванного населения.

Примечательно и то, что в систему султанских законов были включены и элементы римских, византийских, славянских, германских и мамлюкских правовых систем. Однако эти правовые нормы были лишь подмогой к установкам шариата, и они не должны были противоречить его сути.

В Османской империи одним из главных элементов ее могущества были вооруженные силы. Армии были полностью подчинены султану. Они создавались с опорой на могущественных беев, в обязанности которых входило и ведение войн на окраинах империи.

Широкое использование артиллерии, боеспособность пехоты, в особенности янычар, и разумное использование кавалерии обеспечивали стойкое превосходство Османской империи над его противниками.

Османская империя располагала двумя типами войск – «Рабы Порты» и провинциальные войска.

«Рабы Порты» – основная часть армии, представляла собой постоянные отряды милиции, получающие жалование из государственной казны. Они славились дисциплиной, абсолютной преданностью и боевым духом.

Эти войска составляли янычары, артиллерия, кавалерия.

Самую большую часть их представлял корпус янычар, которым командовал ага янычар, подчиняющийся непосредственно султану. Офицеры его окружения составляли Диван корпуса.

Провинциальные войска были рассеяны по территории империи и иногда оставались в стороне от больших походов.

Главную составляющую провинциальных войск составляли сипахи, которые жили за счет обработки земли. Они не платили налоги, но всегда были готовы сражаться, имея при себе оружие, различный скарб и продовольствие, необходимые в походах, не отягощая государственную казну. Они и явились прообразом казачества.

Начиная с эпохи правления Сулеймана Великолепного Османская империя обладала мощным военно-морским флотом, базирующимся на Средиземном море. При этом умело использовали силы и опыт перенявших ислам корсаров, среди которых был и знаменитый Барбаросса (Хайреддин-паша).

Мощь и могущество империи в эпоху правления султана Сулейма-

на базировались на экономической и политической стабильности. Тогда империя представляла собой необъятный рынок, тянувшийся от Польши до Йемена и от Персии до Венгрии, который связывал империю со странами Запада и обширной частью стран Востока.

При этом экономика строго контролировалась. Присутствие государства чувствовалось во всем. При этом четко регламентировались цены, распределение торговых потоков, контроль над экспортом и импортом основных товаров.

Все эти меры защищали подданных султана от нищеты, нужды, дороговизны, безработицы, несправедливостей и были нацелены и на обеспечение мощи государства и увеличения доходов в государственную казну.

Фактически в Османской империи приветствовалось то, чтобы каждый человек имел определенную профессию. Иметь профессию означало быть уважаемым человеком. На самом же деле это считалось всеобщей традицией, присущей всему мусульманскому населению!

Фильм «Великолепный век» восхищает своим изяществом, красотой, четкостью исторических сюжетов. В первую очередь поражает образ султана и его величие, олицетворяющее мощь и могущество Османской империи, А также повсеместные дисциплина и порядок, уважение законов, традиций и преданность им.

Для нас, потомков древних тюркских народов, этот фильм является неким «ликбезом», который пробуждает чувства гордости по отношению к своей истории и уважения памяти своих предков.

Как же можно оценить сущность Османской империи? Случайное ли это явление в мировой истории? На чем основано ее могущество?

При рассмотрении истории тюрков мы видим, что с глубокой древности они создавали свои государства и мощные империи. Их общества всегда обладали неким потенциалом, то есть пассионарностью, которая в определенное время смогла концентрировать, мобилизовать народы и дать им мощный импульс для нового рывка в их развитии.

Например, стоило возвыситься одной благородной ветви определенного рода, племени тюрков, и это могло привести в движение весь тюркский мир. В истории примеров тому много.

Ведь история османов тоже началась с небольшого племени тюрков-огузов, называемых сельджуками. Тюрки-сельджуки принадлежали кланам полукочевых пастухов, живших в шатрах на просторах Средней Азии. Предположительно они являлись предками нынешних туркменов.

Крепость духа в тюрках воспитывался с самого их рождения. На продолжении многих тысячелетий она закладывалась в сознании и генах тюрков!

Примером тому является история Османской империи. Секрет ее могущества и способности процветать на протяжении шести веков объясняет закон пассионарности, открытый в процессе глубокого анализа истории тюрков историком Л.Н. Гумилевым.

А что же мы знаем про историю Османской империи, владычество которой распространялось на территории трех континентов и продолжалось на протяжении шести веков?! Разве то, что османы завоевали Византию и на протяжении веков вели войну с Россией, но не более того.

История и культура эпохи Османской империи всегда привлекали внимание историков стран Запада. Например, в национальных галереях Франции в Гран-Пале и в Версале были организованы

выставки, посвященные времени правления султана Сулеймана Великолепного. В национальном музее замка Трианон были сформированы экспозиции сокровищ и рукописей Османского двора.

Размышляя о расцвете Османской империи, нельзя думать, что она утопала в роскоши именно за счет грабежа порабощенных народов. Под расцветом тут надо понимать процветание науки, образования, культуры, медицины, искусства, ремесел, экономики, различных отраслей хозяйства и общее благополучие в стране.

При этом нельзя забывать и то, что завоеванные страны в границах империи находились под надежной ее защитой и обладали широкой автономией.

Возможно, в процессе создания фильма «Великолепный век» допущены некоторые неточности, просчеты или даже элементы предвзятости. Но в целом он получился изящным, насыщенным историческими событиями, которые будоражат воображение.

В любом случае фильм заставляет думать, размышлять. При этом некоторые моменты вообще трудно воспринимаются – возможно, потому, что от этих событий нас отделяют века, на протяжении которых многое поменялось в жизни и сознании людей. Более того, по истечении времени многие факты перевернуты, преданы забвению или даже сокрыты от нас.

К сожалению, о том, что история татар неразрывно связана с историей турецкого народа и имеет с ней неразрывные культурные и традиционные связи, сейчас мы мало что знаем. Поэтому этот фильм является особенно привлекательным для нас, современных татар.

Сейчас, когда многосерийные фильмы, называемые «мыльными операми», затуманивают мозги людей, отвлекая их сознание от насущных проблем, появление фильма «Великолепный век» восхищает своей изящностью, достоверностью исторических фактов, смелостью сюжета.

Он ворвался в наше сознание, засоренное извращенными интерпретациями событий, прошумевших в прошлых эпохах, как свежий ветер, освежающий его от дурмана.

При этом самым поразительным является то, что автором этого многосерийного фильма является женщина. Сколько смелости, упорства и настойчивости она проявила для выпуска! Ведь ей противостояли серьезные политические деятели и в самой Турецкой Республике, даже сам министр культуры страны! Однако, даже будучи серьезно больной раком, она сумела довести начатое дело до конца.

Самая главная ее заслуга в том, что она смогла чуточку приоткрыть дверь загадочной тюркской истории и так красочно показать одну лишь ее небольшую, но значимую часть – историю «великолепного века», то есть эпохи правления султана Сулеймана Великолепного.

Гөлназ Таипова әзерләде

КӨЗГЕ МУЛЛЫК

Күңелле, кояшлы, чәчкәлеҗиләкле җәйнең үтеп киткәнен сизми дә калдык. Әкрен генә атлап алтын көз килеп җитте. Табигать бер сихри дөньяга әйләнә: тирә-яктагы яшеллек төсен сары, кызыл, кызгылт-сарыга үзгәртә. Күчмә кошлар кышны уздыру өчен җылы якларга китә. Көннәр кыскара, төннәр озая, кояш үзенең нурларын саранрак сирпи, яңгырлар еш ява башлый.

Шулай да көзне яратмый мөмкин түгел, чөнки ул безне кырдагы мул уңышы, бакчадагы алсу алмасы, кызарып пешкән тәлгәш-тәлгәш миләше, баланы, йодрык кадәрле бәрәңгесе, түгәрәк кабаклары белән сөендерә. Көзге муллык. «Язның байлыгы – кояш, көзнең байлыгы – уңыш», дип юкка гына әйтмәгәннәр. Хуҗабикәләр җиләк-җимеш, яшелчә бакчаларында үстергән уңышны эшкәртеп, кышка әзерли.

Укучылар өчен яңа уку елы башланды. Алар җәй буена күрешмәгән укытучылары, дуслары белән очраша, сөйләшә, серләшә. Мәктәпләрдә, балалар бакчаларында көзгә, мул уңышка багышланган төрле кызыклы чаралар уздырыла. Бу затлы чорны – алтынсу һәм бераз ямансу ел фасылын иҗат кешеләре: рәссамнар, композиторлар, шагыйрьләр да ярата.

Мәрзия Фәйзуллина
Көзге яңгыр
– Апа, безгә артыбыздан
Шыбыр-шыбыр кем дәшә?
– Кем дә дәшми, көзге яңгыр
Зонтик белән сөйләшә.

Мәрзия Фәйзуллина
Көзге җил
Көзге җил «усал»,
Салкын булса да,
Колак-борыннар
Бераз туңса да,
Куркытмый безне
Һичбер суык җил.

Ләбиб Лерон
Яфрак бәйрәме
Яңгыр түгел, кар да түгел,
Яфраклар ява җиргә.
Көз турында җырлыймын мин –
Кушыл син яңа җырга.
Сары, сары, сап-сары
Агачның яфраклары.
Җил исә, ява яфрак –
Көзнең матур чаклары.
Оча яфрак, уйный яфрак
Һаваларда әйләнеп.
Бүген, бүген, бүген, бүген
Яфракларның бәйрәме!

Әхмәт Ерикәй
Көз
Көз килде. Үләннәр
Саргайды, шиңде.
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде.

Габдулла Тукай
Бу кайчак була?
Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява;
Җирләр дымлана,
– Бу кайчак була?

Бари Рәхмәт
Кошлар киткәндә
– Сыерчыгым, нигә китәсең?
Сагынырмын сине, киткәчтен.
– Көз җитте бит инде, мин туңам,
Килгән идем җәйге костюмнан.

Габдулла Тукай
Көз
Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.
Китә башлады бездән инде кошлар;
Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.

Кави Нәҗми
Көз
Үтте-китте матур җәйләр,
Көзләр килеп җиттеләр.
Ак каенның яфраклары
Саргаешып киптеләр.

Әминә Бикчәнтәева
Салкын, саф һава
Салкын, саф һава,
Йомшак кар ява.
Урамга чыксаң,
Битләр кызара.
Кар бөртекләре
Өстеңә куна,
Үзләре матур
Һәм салкын була.

Табышмаклар
Катлы-катлы булып үсә
Җир өстендә, ул нәрсә? (Кәбестә)

Йодрык-йодрык булып үсә,
Алма кебек кызарып пешә.
Үзе бик матур, аны кем әйтер? (Помидор)

Ул җир астына төшкән,
Кып-кызыл булып пешкән,
Ашка тәм һәм төс бирер
Аны кем әйтер дә, кем белер? (Чөгендер)

Алма дисәң дә, алалар,
Нәрсә соң ул, балалар? (Алма)

Ашка салсаң, тәм кертә,
Борынга керсә, төчкертә. (Борыч)

Көз турында мәкальләр
Күз өчен яз яхшы, авыз өчен көз яхшы.
Көз бай булма, яз бай бул.
Көз кычкыра: «Уңдырам»,– дип, ә яз әйтә: «Тукта әле, мин нәрсә әйтермен», – дип.
Көзге бозның көзге калынлыгына да ышан, язгы бозның ястык калынлыгына да ышанма.
Көзге катык – көмеш кашык, язгы катык – ярты азык.
Көзге катык, көмеш кашык – кызым белән киявемә; язгы катык, ярык кашык – улым белән киленемә.
Көзге көн ул бала кебек: әле көлә, әле җылый.
Көзге көн – арткы акыл, язгы көн – ярты акыл.
Көзге көн – кияү акылы, язгы көн – яшь килен йөзе.
Көзге көннән язгы төн яхшы.
Көзге юлга кием ал, язгы юлга азык ал.
Яз сөрсәң, көз урырсың.
Яз уңмаган көз уңмас.
Яз яме чәчкә белән, көз яме көлтә белән.
Язгы хезмәт – көзге хөрмәт.
Язның байлыгы – кояш, көзнең байлыгы – уңыш.

ПОКУПАЙТЕ ЖУРНАЛ «САМАР ТАТАРЛАРЫ»

ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР

Телефон для связи 8-917-104-44-45 – **Сайфиев Данияр Ирекович**
Адреса электронной почты – **Samartatarlary@bk.ru, ilyas65@mail.ru**

ПРИОБРЕСТИ НОМЕРА ЖУРНАЛА «САМАР ТАТАРЛАРЫ» МОЖНО ПО СЛЕДУЮЩИМ АДРЕСАМ:
Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»), пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»), магазин «Булгар» (бывший «Итле-сетле») на территории Соборной мечети Самары.

Стоимость текущего номера с доставкой – 250 рублей, стоимость номеров за 2019 год – 300 рублей, все предыдущие номера – по 700 рублей. Доставка журналов по Самаре – тел. 8-937-64-044-77.

УВАЖАЕМЫЕ ЧИТАТЕЛИ!

Каждый год мы выпускаем приложение к журналу «Самар татарлары» – красочный и познавательный календарь татарских дат и событий. В настоящее время начата работа по его составлению, и мы очень рассчитываем на вашу поддержку. В частности, вы можете напомнить нам о предстоящих в 2021 году юбилеях выдающихся представителей татарского народа, круглых датах, связанных с жизнью наших соплеменников, появлением значимых для татар зданий и сооружений и т. д. Ваши предложения вы можете присылать на адрес электронной почты: samartatarlary@bk.ru.

Также календарь, издающийся тиражом 10 000 экземпляров, – хорошая возможность для размещения вашей рекламы, которая будет работать в течение всего года.
Стоимость размещения рекламного блока – от 5 000 рублей (в зависимости от размера блока).
Минимальный размер блока – 3х5 см.
Количество рекламных блоков очень ограничено, поэтому задумайтесь о продвижении ваших товаров или услуг заблаговременно.

По вопросам размещения рекламы обращаться по вышеуказанному электронному адресу или по тел. 8 (917) 104 44 45.
Заявки принимаются до 1 ноября 2020 года.

ГОД ОСНОВАНИЯ 1974

Кулинария

НА РЕВОЛЮЦИОННОЙ

- Праздничные торты и пирожные по индивидуальным заказам
- Готовые изделия из мяса, рыбы, птицы
- Салаты и гарниры
- Охлажденные и замороженные полуфабрикаты
- Большой ассортимент свежей выпечки
- Принимаем заказы на пироги
- Доставка горячих обедов в офис
- Обслуживание банкетов и фуршетов

г. Самара, ул. Революционная, 142
Тел.: 260-10-60, 260-15-60